Шәһри КАЗАН

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 10 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 3 (5181)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«ТАТАРЛАР ИСКИТКЕЧ ТАЛАНТЛЫ»

9 бит

«Татар-Информ»

6 бит

Зифа КАДЫЙРОВА:

«Минем көчем — көчсезлегемдә»

11 бит

Балыкны алганда күзенә кара

КӨН АВАЗЫ

Грипп бер атнадан бетә, күп булса — җиде көннән...

Табиблар әйтүенчә, бу көннәрдә кискен тын юллары вирус инфекциясе һәм грипп белән авыручыларның саны артып киткән. Гадәттә, гриппның ел саен яңа төре барлыкка килә. Аның бер төрлесенә каршы ясаткан прививка икенчесенә каршы тора алмый. Шуңа да авыруга каршы үзебез белгән чаралар белән көрәшергә кала. Ә сез бу юлы гриппка каршы ничек «коралланасыз»?

Гәрәй РӘХИМ, халык шагыйре:

– Инде икенче көн үзем дә авырып ятам. Телевизордан ишетүемчә, быел яңа төрле грипп икән. Табиблар аны ашказаны-эчәк системасы гриппы дип атый. Авырмас өчен җылы итеп киенергә, аякны туңдырмаска кирәк. Авырган очракта бер атна буе өйдә генә яту зарур. Аякка йон оекбаш, өскә дә җылы итеп киенәм мин. Микроблардан котылу өчен тәрәзә җиллеген ачып, бүлмәне җилләтеп торам. Лимон белән туңдырылган кура җиләге салып, кайнар мәтрүшкәле чәй эчәм. Тир белән бергә организмнан микроблар да чыга. Авырганда мунча керергә ярамый. Хәл тагын да авыр булганда табиб та чакыртмый булмый. Мәгълүм мәзәктәгечә, грипп бер атнадан бетә, күп булса – җиде көннән.

Миңгол ГАЛИЕВ, Татарстанның халык артисты:

– Кыр наратбашы, иван-чәй, үги ана яфрагы һәм гөлҗимештән әзерләнгән үлән чәенең файдасын күрәм мин. Аннары Казанда чыккан тугыз процентлы аш серкәсе белән кайнар суны бертигез күләмдә алып, шул катнашмага манылган губка белән тәнемне, борын тишекләрен, колак яфракларын да җиңелчә массажлап ышкыйм. Ярты стакан суга ярты чәй кашыгы сода салып, тамакны чайкыйм. Гомумән, мин менә шуның ише халык чараларын еш кулланам.

Рәмзия ХӘЙРУЛЛИНА, газета укучы:

– Гриппның нинди төре булса да, бөтен ышаныч шул сарымсак белән лимонда инде.

«ШК» газетасының 15 гыйнвар — сишәмбе санына алхәбәр

«Тыңлап бетерүгә исә Илфак абый Ибраһимов: «Ә теге егеткә багышланган мәхәббәт шигырен ник алып төшмәдең?» – димәсенме! Берләшмә җитәкчесе каян белгән, дип минем биткә кызыллык йөгерә».

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. «Алтыдагы – алтмышка»

«Атнага берничә дәрес кенә бушлай кала, калган фәннәрне укыйсы килсә, бала аена биш-алты мең сум түләргә тиеш була, дигән имеш-мимеш ата-аналарны да, укучыларны да, укытучыларны да пошаманга салды. Баланы мәктәптә укыту болай да шактый чыгымлы, инде хәзер аена алты меңне дә чыгарып сала башласаң?»

Фәнзилә МОСТАФИНА. «Закон яңарды, тәртип үзгәрерме?»

Атнага 3 тапкыр чыга торган газетаның индексы – 54126.

ИМАНЫ БУЛСА – КАЙТАРЫР...

7 бит

«ТОРМЫШЫМ КӨРӘШЛӘРДӘН ТОРДЫ»

8 бит

МАХМЫР

10 бит

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Әйләнә-тирә мохитне саклау елы

2013 ел – Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы.

Бу хакта ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Указы бар. Хәер, агымдагы ел тулаем Россия Федерациясендә Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы буларак уздырылачак – бу турыда РФ Президенты Владимир Путин 10 августта махсус Указ имзалаган иде. Ел чарасының төп максаты – һәрбер кешенең әйбәт әйләнә-тирә мохиткә хокукын тәэмин итү, җәмгыятьнең игътибарын әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләренә юнәлтү, халыкның экологик культуралылыгын формалаштыру һәм арттыру, диелә әлеге документларда. Искәртеп үтәбез: былтыр 6 апрельдә Астанада, гомумән, 2013 елны барлык БДБ илләрендә Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы итү турында килешенгән иде. Ул елны нинди чаралар уздыру планы һәрбер илнең үзенеке – анысы һәр ил-субъектның Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланып тормышка ашырылачак, шул исәптән Татарстанда да.

Без бергә эшләргә тиеш

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов Малайзиядә эш сәфәрендә.

Эш сәфәре кысаларында ул Малайзиянең тышкы эшләр министры Дато Сери Анифах Аман белән очрашты. «Сезнең илгә икенче тапкыр зур теләк белән киләм һәм киләчәктә тагын барырга әзермен, чөнки сездә без өйрәнерлек бай эш тәҗрибәсе бар», – дип мөрәҗәгать итте министрга Рөстәм Миңнеханов. Очрашу барышында Татарстан Президенты Малайзия Тышкы эшләр министрлыгы башлыгына Татарстан делегациясенең эш программасы турында сөйләп узды, яклар шулай ук хезмәттәшлекне үстерү перспективалары турында әңгәмә кордылар. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Малайзиягә визиты кысаларында Киберджая шәһәрендә дә булды. Бирегә сәфәрендә ул Малайзиянең Киберджая IT-шәһәрен төзү тәҗрибәсе «Иннополис» проектын гамәлгә ашырырга ниятләүче Татарстан өчен кызыклы булуын белдерде. «Сезнең тәҗрибәгез кызыклы, күп эш башкаргансыз, дөрес юлларны беләсез, сезнең киңәшләрегез безнең өчен файдалы булачак. Без бергә эшләргә тиеш. Киләчәктә сезнең партнерларыгыз булырбыз, дип өметләнәм», – диде Татарстан Президенты.

Иске Яңа елга көтәбез!

ТР Милли музее иске Яңа елны каршыларга чакыра.

Татарстан Республикасы Милли музее казанлыларны һәм башкалабыз кунакларын үзенә төнге бәйрәмгә һәм Идел буендагы иң борынгы музейларның берсенең уникаль тарихи залларында иске Яңа елны каршыларга чакыра. 13 гыйнвардан 14 гыйнварга каршы төндә (22.00-00.30) музейда «Корабтан бию кичәсенә...» дип аталган бәйрәм программасы булачак. Бәйрәм кунакларын көтелмәгән маҗаралар, уеннар, җылы әңгәмәләр, эксклюзив музыкаль программа һәм онытылмас тәэсирләр көтә, дип хәбәр итә ТР Мәдәният министрлыгы матбугат хезмәте.

Кирәк булса, гариза яз

ТАТАРСТАНДА универсаль электрон карта алу өчен гаризалар кабул ителә.

2014 елның 1 гыйнварыннан картадан баш тарту турында документка кул куймаган барлык гражданнарга универсаль электрон карталар бирелә башлаячак. Агымдагы елның 1 гыйнварыннан УЭКны аны рәсмиләштерүгә гариза тапшырганнар ала башлый. Татарстанда «ТР Информацион технологияләр үзәге» ДУПсе «Универсаль электрон карта» ААҖнең тулы вәкаләтле оешмасы булып тора. Ул Петербург урамы, 52, 4 нче катта урнашкан. Барлык сораулар буенча эш көннәрендә сәгать иртәнге тугыздан кичке алтыга кадәр **264-73-00**, шулай ук **511-41-15** телефон номерлары аша шалтыратып була. УЭКны рәсмиләштерүгә гаризаларны Россия Саклык банкы бүлекләрендәге гаризалар кабул итү һәм карталар бирү пунктларында тапшырырга мөмкин.

ЖИР ҺӘМ КҮК

10-17 гыйнвар магнит кыры тыныч булачак.

Чистартмасагыз, штраф түлисез

ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ

Дамир БӘДРИЕВ

Казанда җәен-кышын Кремль урамы һәм Ирек мәйданы гына тиешле дәрәҗәдә җыештырыла. Калган территориядә тоташтан хуҗасызлык хөкем сөрә, дисәк, һич ялгыш булмас.

Автор фотосы

Татарстан Гидрометеоүзәге хәбәрләренә караганда, башкалага 2012 елның декабрендә 69 мм, ә быел гыйнвар аеның тәүге көннәрендә 12 мм кар яуган. «Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев мәгълүмат биргәнчә, кыш башыннан Казан урамнарыннан 167 мең тонна кар чыгарылган. Узган елның 31 декабреннән быелның 7 гыйнварына кадәрге арада чыгарылган кар 40 мең тоннаны тәшкил итә.

Яңа ел каникуллары көннәрендә Казанда, шөкер, автомобиль юллары чистартылды. Ләкин юл читләре буеннан-буена кар «боткасы»на күмелгән иде. Татарстан, Пушкин, Горький, Вишневский, Декабристлар урамнары юллары читләрендә кар өемнәре һаман ята. Бауман урамы кардан яхшылап арындырылмый, «Казан-2» тимер юл вокзалы тирәләрендә тиздән кар.

Мэр Илсур Метшин: «Шәһәрне кыска вакыт эчендә тәртипкә китерергә кирәк», – дип, подрядчы оешмалар һәм шәһәр хуҗалыгы җитәкчеләренә күрсәтмәләр бирде. Тышкы төзекләндерү таләпләрен үтәргә ашыкмаучы предприятиеләргә һәм учреждениеләргә штрафлар салыначак.

Шугалакка чыгар чаклар

ЯЛ

Кышның рәхәте туйганчы чана-чаңгыда, тимераякта шуып калудыр ул, мөгаен. Чанасын аның бер утыргач кем дә шуар, ә менә чаңгы һәм тимераякта әзерлексез генә шуа башлармын димә. Казанның төрле почмакларында эшләп торучы шугалаклар, чаңгы базалары бу эштә сезгә ярдәмгә әзер. **Р.Ваһапов урамындагы ябулы шугалак**та тимераяклар прокаты сәгатенә 50 сум гына тора әнә. Боз өстенә керү зурларга 80 сум булса, 12 яшькә кадәрге балаларга 50 сум тәшкил итә. Өстәвенә һәр якшәмбе 12.30 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр биредә бушлай шөгыльләнергә дә була. Киров районындагы **«Баско» ябулы шугалагы**на барырга теләүчеләр аның бары тик шимбә һәм ял көннәрендә генә һәм 17.00 сәгатьтән 20.30га чаклы гына эшләвен белеп торсыннар. Зурлар өчен боз өстенә керү – 70, балалар өчен 50 сум тора. Бондаренко урамы, 1 нче йорттагы **«Ватан» шугалагы**на керү бәясе – 70 сум. Прокат исә 60 сум. Биредә ял көннәрендә 15.15, 17.00 һәм 18.45 сәгатьләрдә шуарга була. **«Татнефть-Арена» бозы**нда шуар өчен прокатка тимераяклар алу мөмкинлеге хоккей матчларына бәйле. Прокат бәясе 150 сум тора. Үз тимераягы белән килүчеләргә боз өстенә керү 120 сумга чыгачак. Дәрвишләр бистәсенең **Стадион урамындагы ачык шугалак** дүшәмбедән якшәмбегә кадәр 18.30 сәгатьтән 21.30 сәгатькә кадәр эшли. Прокат бәясе – 80 сум, боз өстенә керү 60 сум тора.

Футбол урамындагы **«Локомотив» шугалагы** эш көннәрендә 15.00 дән 20.00 сәгатькә кадәр эшли. Ял көннәрендә ул иртәнге 10.00 дән 20.00 сәгатькә кадәр ачык. Биредә прокат бәясе – 100 сум. Үз тимераягы белән килүчеләр 30 сумга да шуа ала. Ершов урамы, 7 нче йорттагы **«Хезмәт резервлары»** эш көннәрендә 17.30дан 21.00 сәгатькәчә эшли. Ял һәм бәйрәм көннәрендә 12.00дән 21.00 сәгатькә кадәр ачык була. Биредә зурлар өчен тимераяк прокаты – 100, 14 яшькәчә балалар өчен – 50 сум. Боз өстенә керү зурларга 60 сум булса, 7 яшькә җитмәгән балалар өчен бушлай. Эш көннәрендә прокат – 10.00дән 17.00 сәгатькә кадәр, бәйрәм һәм ял көннәрендә исә 9.00дән 17.00гә кадәр эшли. Бер сәгатькә прокат бәясе – 100 сум. Иң билгеле чаңгы базаларының берсе, мөгаен, **Дубравная урамындагы база**дыр. Биредә чаңгы прокатының беренче сәгате – 120, икенче сәгате 90 сум тора. Аккош күле тирәләрен чаңгыда әйләнергә теләүчеләр өчен «Динамо» чаңгы базасы бар. Ул 10.00дән 15.00 сәгатькә кадәр эшли. Дүшәмбе – ял көне. Биредә пластик чаңгыларны – 150, агач чаңгыларны 80 сумга алып торырга була. Дәрвишләр бистәсенең **Парк урамындагы база** сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә 15.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр, ял көннәрендә 10.00дән 16.00 сәгатькә кадәр эшли дип белдерә «АиФ-Казан» басмасы.

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ,
ТР Президенты:

— Автомәктәпләр, машина йөртү хокукын штамплап, полуфабрикат йөртүчеләрне юлга чыгара.

(«2006-2012 елларда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү» максатчан федераль программасы үтәлеше нәтиҗәләре буенча уздырылган утырышта әйткән сүзләре)

ЯҢАЛЫК

Нәүрүз бәйрәме — Урман көне

Быелдан башлап истәлекле көннәр календаре тагын бер үзенчәлекле бәйрәмгә байый бит әле. Яз көне без Урман көнен билгеләп үтәчәкбез. Халыкара Урман көнен гамәлгә кую идеясен БМО карамагындагы Бөтендөнья Азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы оешмасы хуплап чыкты. Гамәлгә куелган Халыкара Урман көне әле төркиләр һәм иранлыларның Нәүрүзенә туры килә. Шул рәвешле, астрономик кояш календаре буенча төркиләр һәм иранлыларның Яңа елы – Нәүрүз көнендә тагын бер истәлекле дата гамәлгә куелды. Бу хакта ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы хәбәр итә. Татарстан биләмәләренең бүген 17 процентдан артыгы – урманнар. Халыкара Урман көненең төп максаты исә – халыкның урман экосистемалары әһәмияте, аларның хәзерге хәле, аларны саклауда, үстерүдә һәм торгызуда төп чаралар турында мәгълүматлылыгын арттыру. Биологлар билгеләп үткәнчә, урман мәйданнарының кими баруы глобаль әһәмияттәге тискәре процессларга китерә. Нәтиҗә буларак, туфрак эрозиягә дучар була, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы төрлелеге кими, сулыклар, атмосфера һавасы пычрана, сәнәгать һәм ягулык максатларына ярашлы агач күләме кими.

Мөселман сәгатьләре сатыла

ИШЕТТЕГЕЗМЕ?!

Казанлыларга интернет-кибеттә мөселман сәгатьләрен сатып алырга киңәш итәләр. Аның механизмын будильнигы намаз вакытын хәбәр итәрлек итеп көйләргә була.

Цифрлы мөселман сәгатьләре тышкы ягы белән калган сәгатьләрдән берничек тә аерылмый: көмеш төсендәге корыч браслет, өч ук, гарәп язулы кара циферблат һәм электрон табло. Соңгысы ярдәмендә намаз вакытын көйләргә була.

Сатучылар ышандыруганча, сәгать ярдәмендә кыйбла ягын да, үз җирлегең яки башка шәһәрләр өчен һиҗри һәм Григориан календаре буенча вакытны да билгеләргә мөмкин. Әлеге техника могҗизасы сатып алучыларга якынча 2,5 мең сумга төшәчәк.

Грипп эшкә керешкте!

Казанда 3-6 яшьлек балалар арасында ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны эпидемия бусагасыннан 3 тапкырга артып киткән.

СӘЛАМӘТЛЕК

Яңа ел бәйрәмнәрен табын артында түгел, ә урын өстендә үткәрүчеләр, чыннан да, күп булган бу көннәрдә. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе Рамил Әхмәтов әйтүе буенча, бәйрәм көннәрендә ашыгыч ярдәм хезмәтенә мөрәҗәгать итүчеләр 1 тәүлеккә 1500-1600гә хәтле җиткән. Бу беренче чиратта грипп һәм ОРВИ белән авыручыларның артуы белән бәйле. Олылар арасында авыручылар саны эпидемия бусагасыннан 24 процентка, 3-6 яшьлекләр арасында ул 3 тапкырга артып киткән.

РФнең баш санитар табибы Геннадий Онищенко да, грипп шаукымы Яңа ел бәйрәмнәреннән соң күзәтеләчәк, дип кисәткән иде. Авыручыларның көннән-көн артуы да шуңа дәлил. Шуңа күрә бүгенге көндә саклык чараларын үтәү аеруча мөһим. Барыбыз да белгән берничә төп кагыйдә – һәрдаим кул-борыннарны юып тору, кеше күп җыела торган урыннарда йөрмәү, иммунитетны күтәрү өчен витаминнар эчү, суган-сарымсак ашау һ.б. сезон авыруыннан сакланырга булышмый калмас.

Иманы булса — кайтарыр...

Мин яңа ел төне могҗизасына ышанмыйм. Шулай да бу яңа ел төне алдыннан үземә-үзем көтелмәгән тетрәнү ясадым. Әлеге вакыйганы Аллаһның кисәтүе буларак кабул иттем мин.

БУЛГАН ХӘЛ

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Хәл болай булды: 28 декабрь көнне дус-ишләр белән җыелышып шактый озак вакыт аралаштык. Бәйрәм төнен кайда-ничек үткәрү турында уйлашасы, фатир мәсьәләсен дә кайгыртасы бар иде. Шулай итеп, бер иптәшебез арендалап торучы ике бүлмәле фатирны карап кайтырга ниятләгән арада метродан кала җәмәгать транспортлары инде йөрүдән туктап та өлгергән иде. Без, биш кеше, Тукай мәйданы тукталышына «мотор» тотарга юнәлдек.

Мин каршыма туктаган «бомбила» белән сатулашып торган арада икенче иптәшем түбәсендә шашкасы булган көмешсу 11ле машина хуҗасы белән Роторный тукталышына тиклем 150 сум бәягә бару турында килешеп тә өлгерде һәм без, кысыла-кысыла, машинага төялә башладык. Кысан салонда комачау итмәсен дип, ноутбук һәм башка кирәк-яраклар тәялгән букчамны арткы панельгә алып куйдым һәм, кызып-кызып, машина хуҗасы белән танышырга керештек. Яңа танышым Николай чыгышы белән Чуашстан башкаласыннан булып чыкты. Чуаш абзыйның Никита исемле 6 яшьлек улы да бар икән... Тел, милләт һәм башка мәсьәләләр хакында аралашып барган арада саубуллашыр вакыт та килеп җитте: берберебезгә юл куешып, кысан салоннан коелыштык... Фатирга кереп чишенә башлагач, ноутбук букчасы исемә төшмәсенме! Машинада киткә-ә-ә-н!!! Нишлибез??? Анда бит, ул букчада бит күпме мәгълүмат, күпме кирәк-ярак. Барлык язмалары белән диктофон, иң кирәкле номерлар язылган иске телефоным, фотоаппарат флешкалары, киләсе язмаларым өчен материал җыйган блокнотлар, ноутбукның үзе турында әйткән дә юк. Кыскасы, ни маңгаендагы шашкасының төгәл саннары, ни дәүләт номеры истә калмаган билгесез машинага утырып ярты байлыгым һәм алдагы планнарым билгесез тарафка китеп югалды... Вәт ачык авыз!!! Күп көлсәң – бер елыйсың, дигән сүз дөрес икән, ул көннәрне сабый бала сыман артык күп шукландым шул. Ә шуклык игътибарны киметә.

АХЫРЫ 7 НЧЕ БИТТӘ

Илдә ниләр бар икән?

ВАЗГЫЯТЬ

Тагын ахырзаман куркынычы?

21 декабрьдә ахырзаман булмыйча калды. Хәзер кешелек дөньясы зур түземсезлек белән 2029 елның апрелен көтә. Бу вакытта өч йөз метрлы Апофис астероиды геостационар иярченнәр орбитасы биеклегенә якынлашырга, ягъни Җир шарыннан нибары 36 мең километр тирәсе ераклыкка җитәргә тиеш. Галимнәр Җир шарына болай якынайган Апофис орбитасын үзгәртергә мөмкин дип борчыла. Ә бу юл була калса, 2036 елны янә әйләнеп кайтканда аның Җир шарына килеп бәрелү ихтималы бар. NASA пресс-релизы хәбәр итүенчә, Җир шарына куркыныч тудырырга мөмкин булган бу планета киләсе чәршәмбедә планетабыздан 14,46 миллион километр ераклыкта узачак. Бу мизгелне «Slooh.com» сайты камерага төшереп, бушлай трансляцияләргә җыена.

Кар бәрешсәң — тоткарлыйлар

Санкт-Петербургта кар бәрешеп уйнау флеш-мобы узган. Нәтиҗәдә, кышкы акциянең кайбер катнашучыларын полиция алып киткән.

6 гыйнвар көнне йөздән артык яшь кеше кар бәрешеп уйнарга җыелырга була. Ләкин уен башланып бераз вакыт узгач, бәйрәмгә полиция килеп кушыла һәм чаранын шәһәр хакимияте белән килештерелмәгән булуын әйткерә, яшьләрне таралышырга чакыра. Флешмобны оештыручыларның берсе: «Полиция барысын да куды, кәефне кырды, ә берничә кешене хәтта «Газон буйлап йөргән өчен» дип, участокка алып китте», – ди. Яшьләр уенга Марс мәйданына, Петербургның рәсми Гайд-паркына җыйналган була. Шәһәр башлыгы Георгий Полтавченко күптән түгел бу урында йөздән күп булмаган кеше генә хакимият белән килешмичә җыелырга хокуклы дигән постановлениегә кул куйган була.

Ятим нигә асылынган?

Татарстанда яшәүче бер төркем кеше балалар хокукын яклау буенча вәкаләтле вәкил Павел Астаховка ачык хат белән мөрәҗәгать иткән. Алар балалар хокукын яклаучыдан декабрь аенда асылынып үлгән 15 яшьлек малайның эшен тикшерүне контрольгә алуны сорый. Лаеш районындагы бер гаиләдә тәрбиягә алынган малайның үлеме җирле халыкны зур борчуга салган. Интернетта киң таралган мөрәҗәгатьтә, бу вакыйгада үги әти-әни җавап тотарга тиеш, диелә.

Ачык хатта язылганча, малайны чоланга бикли торган булганнар, тәүлек буе ашатмаганнар һәм кыйнаганнар. Бу хакта, имеш, күршеләр, һәм малай үзе дә күп тапкыр социаль яклау хезмәтенә мөрәҗәгать иткән. Элегрәк ТР тикшерү комитеты малайның үзенә кул салуының төрле сәбәпләре тикшерелә дигән иде. «Интерфакс» шундый сәбәпләрнең берсе итеп егетнең Суворов училищесына алмауларын атый.

Күктә дә тынгы юк

Яңа елны ничек каршы алсаң, аны шулай үткәрерсең, ди халык гыйбарәсе. Ел башыннан дөньяда булырга өлгергән авиаһәлакәтләрнең санына күз салсаң, бу сүзләрдә хаклык барлыгына инанмыйча хәлең юк. 2013 елның әле ун гына көнен яшәдек, шул арада кеше гомерләрен алып киткән биш авиаһәлакәт булды. Яңа елның шулай башланып китүен 2012 ел азагындагы Россиядәге авиафаҗәт үз койрыгына ияртеп килмәдеме икән, дигән уй башка үзеннән-үзе килеп керә.

«Хыял лайнеры» да яна башлаганны

Рәсми булмаган, бары тик сынамышлар юрамаларына буйсынган канун буенча, бы елгы авиаһәлакәтләрнең ихтимал сәбәпчесе – узган елның 29 декабрендәге Мәскәүнең «Внуково» аэропортындагы күңелсез вакыйга. Ул көнне очуын тәмамлап, аэропортка утырырга җыенган Ту-204 самолеты полосада туктап бетә алмыйча, киртәләрне җимереп, читкә шуган иде, 5 кеше һәлак булды.

Быелгы авиафаҗәгатьләр сериясе исә 1 гыйнвар көнне АКШның Алабама штатындагы җиңел моторлы очкычның җиргә бәрелүеннән башланып китте. Өч үсмер егет үз башларына мажара эзләп, очуга рөхсәт сорамыйча гына, самолетны күккә күтәрәләр, күңел ачарга теләүләре аларның өчесенең дә гомерләрен өзә. 2 гыйнвар көнне Израильдә аздан гына куркыныч авиаһәлакәт булмый кала. Полосага утырырга җыенган хәрби очкычның очучысы белән штурманы вакытында төзексезлекне сизеп алып, катапульта төймәсенә басарга өлгерәләр, нәтиҗәдә машина гына зыян күрә. 4 гыйнвар иртәсендәге авиаһәлакәткә бәйле күңелсез очрак үзәгендә янә АКШ, янә шәхси очкыч һәм янә өч корбан. Бу юлы Флорида штаты күге буенча очкан зур булмаган аппарат яна башлап, шәхси йорт өстенә ава. Самолет бортындагы өч кеше дә һәлак була, йорт хуҗасы могҗиза белән генә исән кала. Чираттагы авиаһәлакәт 5 гыйнвар көнне Франциияне яңгыратты. Шулай ук зур булмаган самолет әлегә ачыкланмаган сәбәпләр аркасында, кинәттән биеклеген югалта һәм тау сыртына килеп бәрелә, анда очкан 5 кеше дә һәлак була. 7 гыйнвар төнендә Перуда вертолет катнашындагы авиаһәлакәт 7 кешенең гомерен өзде.

Бу авиаһәлакәтләрдән тыш, яңа елның һәр көнендә диярлек төрле илләрдә самолетлар белән зур бәлаләргә китерен җиткермәгән хәлләр дә булып торды. Очу барышында ниндидер төзексезлекләрне сизеп алып, дистәләгән пассажирлы очкычлар Казан, Лондон, Тольятти, Судан, Самара, Түбән Новгород аэропортларына кичектергесез туктарга мәҗбүр булдылар, Кариб диңгезендә 6 кешелек самолет эзсез югалды, Саранскида бортында хоккей командасы булган очкыч полоса читенә тәгәрәде, АКШның Бостон шәһәрендә «Хыял лайнеры» дигән атама алган боинг янды.

Күкләребез тыныч булсын иде

Бүгенге заманда күпчелек халык сәяхәт өчен һава юлларын сайлый. Бу карарда хәлиткеч рольне уңайлылык, юл газапары булмау, тизлек факторлары уйный. Бер яктан караганда, һавада һәлакәткә юлыгу ихтималы җирдәгегә караганда күпкә азрак. Очып барган самолет каршына көтмәгәндә каяндыр кеше йөгереп чыга алмый, аңа башка самолет килеп бәрелү мөмкинлеге минималь, ниндидер киртәләр, агачлар, биналар, күперләр, тайгак юллар да юк. Тик шул ук вакытта бер әйбер самолетта очуны җир транспорты белән чагыштырганда күпкә хәтәррәк итә – һәлакәт була калган очракта, исән калуга шанслар 1 проценттан да азрак.

Авиафаҗәгатьләрне гадәттә төп өч фактор китереп чыгара – аппаратның төзексезлеге, очучының игътибарсызлыгы һәм һава торышы шартлары. Иң тиз һәм уңайлы сәяхәт исулы иң куркынычсызына да әйләнсен өчен, очкычны күккә очырыр алдыннан, аны аннан-моннан гына түгел, җентекләп тикшерү, штурвал артына өйрәнү дәверендә тиешле очу сәгатьләрен алган очучыларны гына утырту, һава торышлары белән дөрес исәпләшү кагыйдәләрен генә намуслы үтәргә өйрәнәсе калды.

Гомуми исәп ясасак, яңа ел башыннан 5 авиаһәлакәт теркәлеп, 18 кеше һәлак булган, 8 авиафаҗәт аздан гына булмыйча калып, 1000гә якын кешене Ходай саклаган, 6 кешелек бер очкыч югалган. 10 көн өчен күп бит инде бу. Теләсәң-теләмәсәң, ирексездән башта әйткән гыйбарә турында уйлап куясың.

Сөн буеның ап-ак каеннары...



ГИМН

Әй, кайчак үз туган ягыңның да гүзәллеген күреп бетермисең инде. Актанышның Меңнәр авылына баргач та мин берара әсәренеп, гаҗәпсенеп тордым. Булса да була икән матур, нур йоккан чын татар авыллары. Урамнарында да, ихаталарында да төзеклек, буяу тимәгән, бизәк төшмәгән бер йорт, бер тәрәзә юк. Хан сарайлары түгел, әмма бар җирдән ниндидер җылылык, бәрәкәт, нур бөркелеп тора. Урамда башта бит очларын алсулатып чаңгыда килүче егетне очратсам, аның артыннан ук тимераяк кигән 6-7 яшьлек кыз каршы чыкты. Баксаң, аңа яңа тимераяклар бүләк иткәннәр икән, бозга төшкәнче, авыл урамында сынап карамаска әллә...

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА,
Актаныш, Меңнәр

Киртләчләп көрәлгән капка төпләренә, тымызык кына күккә күтәрелгән морҗа төтеннәренә биһуш булып атлый-атлый, балалар бакчасына килеп төртелгәнемне сизми дә калганмын. Балалар бакчасы ишегалды Казанныкылардан ким түгел, әй – шундый ук, кырыкмаса-кырык төрле спорт инвентаре белән мактанып, төрле төсләргә баеп утыра. Өч бала белән каршыма чыккан хатын-кызны тәрбияче дип уйлаган идем. Ул исә җәһәт кенә аңлатып та китте: «Бакчада эшлим эшләвен, әмма болары үземнеке: бусына – 6, боларына 3-4 яшь. Өч бала баламы инде ул? Минем әле өлкәннәре дә бар. Җәмгысы алтау.» Мин аларны, «әни, әни, әни», дип урам тутырып гөрләшә-гөрләшә баруларын күздән югалганчы озатып калдым. Күз генә тимәсен!.. Ә үземнең бит шушы авылга килен булып төшкән авылдашым, күптән түгел генә юбилеен бәйрәм иткән Фәнисә апаны эзләп килешем. «Яшь вакытта авылда калудан, колхозда эшләүдән котым чыга иде. Ә бәхетем нәкъ авылда, янәшәмдә көтеп торган икән», – дигән иде ул бер юлы. Аның Меңнәр авылында яшәвенә дә өч дистә елдан артып киткән икән инде.

– Алай да язмыш миннән акыллырак булып чыккан да, алай да авылда калдырган, дип шөкер итәм бүген, – дип көлә-көлә сүзен башлады Фәнисә апа Низамова, үзенең гомер юлына бәя биреп. – Мин 1962 елда, дүрт апам, бер абыемнан соң көтеп алынган, иң кечкенә апамнан соң алты ел аерма белән дөньяга килгән кыз. Яңа Әлем кызы. Университетка бер талпынуда керә алмадым да, беренче очраган трамвайга утырып, техник вуз ишеген шакыдым. Укуны тәмамлаганда, 27 яшьлек идем инде. Колхозга эшкә барасы килмәде. Әлем авылының балалар бакчасына эшкә урнаштым, соңрак Уразайда эшләдем. Әмма ул вакытта билгеләү дигән нәрсә бар иде. «Чишмә» колхозына зоотехник итеп эшкә чакырдылар. Әле дә хәтерлим: 26 март, беренче эш көнем. Ә минем колхозда эшлисе килмәвем итәк-чабуымнан коела-коела бара... Шөкер, бергә эшләүче белгечләр әйбәт булды. Озакламый зур «Чишмә»дән ике хуҗалык ясадылар. Соңрак хуҗалыклар кабат кире кушылды. Мин тиз арада икътисадчы һөнәрен үзләштердем дә, инде озак еллар колхозда шушы вазифаны башкарам.

– Сез бит инде бу вакытта ир хатыны?

– 1989 елда шушы авыл егетенә кияүгә чыктым. Бер кыз, бер малай алып кайттык. Хәзер улыбыз Алмазга – 23 яшь, Түбән Кама шәһәрендә яши, кызым Рамилә югары уку йортында белем алып йөри. Ирем колхозда механизатор булып эшли. Авылда икебез генә хәзер.

– Теге мәңге авылда яшәмәс идем, дигән уй кыбырсып алгаламыймы соң, Фәнисә апа?

– Син нәрсә, Меңнәрдән дә матуррак җир була аламы соң? Без бит әле шуның өстенә авыл читендә, Сөн ярында диярлек яшибез. Ә ярда кукраеп каеннар утыра. Язын ямь-яшел яфрак яруларын, көзен җете кызыл булып өлгергән ябалдашларының шәфәкъ баешында назланып утыруларын бер генә күр син! Төрле вакыт булгандыр – авылга кайтасы килмәгән вакытымны да уйлап алган чак була. Әмма мин бүген анык беләм – авылсыз яши алмыйм инде хәзер. Шәһәр ыгы-зыгысыннан Ходай сакласын. Мин – табигатем белән авыл баласы. Һәм шундый бәхет һәркемгә насыйп булуын теләр идем.

Уҗымнарга тагын куркыныч яный

БОРЧЫЛУ

Әле кайчан гына, көз айлары җылы килү һәм яңгырлы булу аркасында, уҗым культураларының артык нык үсеп китеп, киләсе ел уңышы өчен борчылырга мәҗбүр итүе турында язып үткән идек. Инде агрономнар тагын киләсе елның уңышы өчен хәсрәтләнә.

Табигать үзенең сюрпризларын әзерләп кенә тора шул, бер дә без фаразлаганча килеп чыкмый. Декабрь аенда булган көчле салкыннар (кайбер якларда һава температурасы хәтта 30 градуска кадәр җитте) уҗымнар өчен бер дә файдалы булмады. Өстәвенә ул вакытта кары да җитәрлек яумаган иде. Бигрәк тә Идел буе һәм Кама аръягында хәлләр борчуга сала. Бу тагын киләсе ел уңышын куркыныч астына куя. Шуңа күрә ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Минсәгыйрь Нуртдинов запаска дигән орлыкларның һәрвакыт булырга тиешлеген искәртте. Яз айлары менә-менә килеп җитәчәк, бу вакытка барысы да әзер булырга тиеш.

Белгечләр шулай ук июнь аеның беренче яртысында – үсемлекләргә дым иң кирәк вакытта – яңгырларның аз яву ихтималын да билгеләп үтә.

«Акча түләп, чүп үстерү хуҗа эше түгел»

Республикабызның кайбер авылларына барсак, бернәрсә чәчелмәгән, инде күп еллар файдаланылмаган буп-буш җирләрне очратырга була.

КАРА-КАРШЫ

Аларны күрү бик кызганыч. Кулланылышта булмаган авыл хуҗалыгы җирләре өчен җир салымы нормаларны моңарчы кадастр бәясенең 0,3 процентына тигез булса, алга таба РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы аны 1,5 процентка кадәр арттырырга дигән тәкъдим белән чыккан. Президент Владимир Путин да әлеге тәкъдимне хуплый, дип хәбәр итә ПРАЙМ икътисад мәгълүматлары агентлыгы. Әлегә закон проекты карала гына. Әмма ул гамәлгә керә калса, сезнеңчә уңай якка үзгәреш булачакмы?

Сания Каюмова, Мамадыш:

– Салым бермә-бер артып, кесәгә суга башлагач, җир хуҗалары уйланыр, мөгаен: ул аны йә сатып җибәрер, йә табыш алырлык итеп эшкәртә башлар. Акча түләп, чүп үстереп яту һич хуҗа эше түгел инде ул.

Тимур Ибраһимов, Казан:

– Шәһәрдә җир өчен сугышып ятканда, авылда аны әрәм итеп буш тотуны күз алдына китерүе дә кыен. Җир акча бит ул! Кулланмаган очракта, һич югы сатсыннар. Печән өстендә яткан эт кебек булмасын инде...

Авыл кешесе моны каян аңласын?!

Италиянең экс-премьеры Сильвио Берлускони 20 ел бергә яшәгән хатыны Вероника Ларио белән аерылышырга булгач, өч ел буе дәвам иткән суд эше үзенең карарын чыгарган: сәясәтче элеккеге хатынына ай саен (!) 3 млн евро акча түләп торырга тиеш.

МӨНӘСӘБӘТ

Чулпан НӘҖИПОВА

Әлеге яңалык авыл халкы арасында да таралды, әмма алар моны һич кенә дә аңлый алмады. Мондый акчаларны өндә түгел, төштә дә күрмәгән, гомер буе 4-5 мең сумга эшләгән авыл кешеләре арасында, ялгыш ишеткәнбездер, дип, хәбәрне кат-кат тыңлаучылар да, бәлки, бу айга түгел, ә елынадыр дип, ничек тә булса аңларга тырышучылар да булды. 3 млн евро түгел, 3 меңгә яшәп карасын иде алар. Авыл кешесе әле дә тырыша-тырмаша инде: хезмәт хакына гына карап утыра торган түгел шул. Юрганыңа карап, аягыңны сузасың дигәндәй, авыл кешесе әллә ни хыялларга бирелмичә, очын-очка ялгый алса, шуңа риза булып яши бирә. Мал асрап, сөт сатып, яшелчә үстереп, ничек тә тормышын алып бара. Дөньяда акчадан да зуррак кыйммәтләр бар бит әле...

Бүгенге көндә авыл җирендә эшләүчеләрнең хезмәт хакына килгәндә, үткән елның нәтиҗәләре буенча, алар уртача 12 мең сум акча ала. Бу, республика икътисадындагы уртача хезмәт хакына караганда, 2 тапкырга азрак. Эре комплекслар урнашкан районнарда уртача хезмәт хакы югарырак, билгеле, 18-20 мең сумнар тирәсе. Әмма 8-9 мең сумга эшләүче районнар да, алар арасында 5-6 мең сум гына алучы хуҗалыклар да җитәрлек. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов Хөкүмәт йортында узган атналык киңәшмәдә шундый саннар китерде, дип күрсәтә «Татар-информ». 5-6 мең генә түләүчеләргә карата ул: «Бездә эшсезлек буенча пособиене дә шулкадәр түлиләр. Ә монда тулы айлык хезмәт хакы», – ди. Ул, бу мәсьәләдә вазгыятьне тамырдан үзгәртергә кирәк, стимул бирүне саклау мөһим, дигән фикердә тора.

Сәхифәне
Чулпан НӘҖИПОВА
әзерләде

Мине борчый

... яр буенда бар да бар

Казанда океанариум барлыкка киләчәк, диләр. Кай тирәдә булыр икән ул?

Галия Садриева, Лаеш

Океанариум ясау мәсьәләсе күптән түгел Казансу ярларын төзекләндерү кысаларында каралды, дип хәбәр итә «АиФ» газетасы. 189 гектар мәйданны биләгән кишәрлектә шәхси йортларны күчерү күздә тотыла. Чистай, Әмирхан, Декабристлар урамнары арасында гомуми мәйданы 500 мең кв.м булган 10 катлы торак массив калкып чыгачак. Шулай ук Казансуның уң як ярында мәктәпләр, балалар бакчалары, дәваханәләр, океанариум, кафе, рестораннар, сәүдә үзәкләре һәм күпкатлы машина кую урыннары төзеләчәк. Төзелеш эченә яңа Никахларны теркәү сарае да керә. Анысы Универсиада вакытында медиаүзәк буларак кулланылачак.



... номерыңны калдыр әле

Казан автомобильчеләрен алгы тәрәзә чистарткычлар астына кесә телефоны номерларын ябыштырып куярга мәҗбүр итәчәкләр икән диләр. Ни өчен икән?

Марат Солтанов, Казан

Дөрестән дә, Казан ЮХИДИ идарәсендә шундый тәкъдим яңгырады дип белдерә «АиФ Регион» газетасы. Юл инспекторлары кешеләрне мәҗбүр итмиләр, бу эш ирекле рәвештә эшләнә. Бигрәк тә машиналарын юл читенә генә туктатып китәргә яратучыларга кагыла ул. Кагыйдәләрне бозып юл читенә туктатып калдырылган машиналар башка автомобильләргә һәм җәмәгать транспортына комачаулык тудыру белән беррәттән юлдагы карларны чистарту техникасына да каршылыклар ясый. Үз вакытында һәм тиешенчә чистартылмаган юллар исә юллар тараюга һәм бөкеләргә китерә. Машинаның алгы тәрәзәсендә хуҗаның телефон номеры булган очракта, эвакуатор чакыртып торганчы, турыдан-туры хуҗага шалтыратып, машинасын алып куюын сорарга да булыр иде.

...ябыгасың килсә, китап укы

Китап укуның организмга булган файдасы спорт белән шөгыльләнүнекеннән калышмый дип укыдым. Хәтта ябыгырга да булыша, имеш. Бу дөресме икән?

Алия Данилова, Казан

Британиянең Сассекс университеты галимнәре стресс белән көрәшүнең даруларсыз ысулларын өйрәнгәннәр һәм әдәби китап укуның стрессны 68 процентка киметүен ачыклаганнар. Шулай ук талгын матур музыка тыңлау стрессны – 61 процентка, яңа пешерелгән хуш исле чәй эчү – 54 процентка, ә саф һавада йөреп керү 42 процентка кимәтә икән. Кызыклы китапны 6 минут кына уку да стресс кичергәннән соң организмга нормага кайтырга мөмкинлек бирә. РФ Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе укытучысы психолог Дмитрий Воедилов сүзләренчә, йотлыгып укыганда хәрефләр һәм сүзләргә игътибар бетеп, тулысынча сюжетка кереп китү күпләргә таныштыр. Кеше виртуаль дөньяда ереп бетә, шунда яши башлый дисәң дә була. Нәтиҗәдә бәхет гормоннары эшләп чыгарыла яки адреналин күтәрелә. Әгәр китап гадәттән тыш кичерешләргә китерсә, кеше хәтта ябыгырга да мөмкин.

... бездә күп туалар бит

2013 елның 1 гыйнварыннан Россиянең 50 регионында өченче яки аннан соң туган балалар өчен айлык пособие түләнә башлаячак, имеш. Ул кайсы регионнарда кертелер икән?

Миләүшә Мусина, Буа

«Российская Газета» мәгълүматларына караганда, өченче яки аннан соң туган балаларга пособиеләр Карелия, Коми, Мари Эл, Мордовия, Чувашия республикаларында, Алтай, Камчатка, Пермь, Приморье, Ставрополь, Хабаровск крайларында, Амур, Архангельск, Белгород, Брянск, Владимир, Волгоград, Кострома, Курган, Курск, Ленинград, Липецк, Магадан, Мурманск, Нижний Новгород, Омск, Оренбург, Орлов, Пенза, Псков, Ростов, Рязань, Самара, Саратов, Сахалин, Смоленск, Тамбов, Тверь, Тула, Ульяновск, Ярославль һәм Яһүд автоном өлкәсендә түләнәчәк. Бу регионнарда балалар туу саны ил буенча уртача күрсәткечләргә караганда түбәнрәк.

... дельфиннарсыз да булмый

Украина хәрби диңгез флоты өчен диңгез хайваннарын әзерләү буенча махсус программаны кабат торгызган диләр. Флотка дельфиннар нәрсәгә?

Таһир Дәминов, Казан

Украина ХДФ вәкилләре сүзләренә караганда, бүгенге көндә 10 дельфин махсус өйрәнү уза икән. Диңгез хайваннарын совет флоты хаҗәтләре өчен Севастопольдә 1973 елда әзерли башлаган булганнар. (Сүз уңаеннан, хәрби дельфиннарны әзерләү үзәкләре дөньяда бары тик икәү генә. Икенчесе – Калифорниядә.) СССР таркалгач һәм Кара диңгез флоты бүленгәннән соң, дельфиннарны әзерләүче океанариум Украина ягына күчте. Океанариумның үзендә махсус программа турында сөйләргә теләмиләр, дип хәбәр итә «АиФ» газетасы. Шулай да алар дельфиннарны су асты миналарын эзләргә өйрәтүләрен белә алганнар. Башларына беркетелгән пычаклар ярдәмендә дельфиннар хәтта диверсантларга да һөҗүм итә ала. Әмма алардан камикадзе ясарга җыенмыйлар – дельфиннар бик кыйммәткә чыга. Кагыйдә буларак, дельфиннарга куелган бурыч – төп максатларның координаталарын ачыклау. Мурманск диңгез биологиясе институты белгечләре сүзләренә караганда, алар өйрәтүгә җиңел биреләләр – берничә ай эчендә зур уңышларга ирешергә мөмкин. Мондый база РФдә дә бар: Кольск култыгында шундый максатлар өчен тюленьнәрне өйрәтәләр.

... эчәргәме, юкмы

Табиблар кешене эчкечелеккә этәрә торган генны ачыклаганнар дип ишеттем. Бу ачышның берәр файдасы булырмы икән?

Лилия Зарипова, Казан

Лондондагы Королева колледжы галимнәре әлеге генга ия булган кешеләрнең спиртлы эчемлекләрдән ләззәтне күбрәк алуларын ачыклаганнар. Димәк, алар калганнарга караганда эчкечелеккә тизрәк бирешергә мөмкиннәр. Табиблар фикеренчә, бу ачыш эчкечеләрне дәвалауда һәм кешеләрне тормыш төбенә төшүдән саклап калуда зур роль уйнарга мөмкин. Безнең галимнәр инде эчкечелеккә бирелүчәнлеккә генетик анализ алымын да эшләделәр. Кан анализы буенча кешегә спиртлы эчемлекне татып караргамы, әллә кабып та карамаскамы икәнлеген белеп булачак. Бүгенге көндә, статистика мәгълүматлары буенча, халыкның 30 процентына алкоголь куллану куркыныч, тагын 10 процентына зыянлы, дип белдерә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының баш наркологы Евгений Брюн.

... матур сан — «лотерея билеты»



Машиналардагы «777», «999» кебек матур саннарны хәзер кемнең кем икәнлегенә карап тормыйча бирәчәкләр, диләр. Бу чыннан да шулаймы?

Идрис Мәгъсүмов, Зәй

Машинаны теркәгәндә миңа тегe яки бу саннар кирәк дип инспектор янына килеп булмас кебек. Билгеле, рәсми төстә. Әмма теләге булганнар нәкъ менә үзләренә кирәкле номерны кулларына төшерер өчен 100әр мең сум акчаларын да кызганмыйлар. Хәзер дәүләт номеры «лотерея»га әйләнәчәк. Өч җиделе яки тугызлы саннарын яхшы чит ил машинасында да, искереп беткән «Жигули»да да күрергә мөмкин булачак. Инспекторлар кайберәүләргә кирәкле саннарны биреп ришвәт алмасыннар өчен, дәүләт номерларын хәзер «машина» бирә башлаячак, диләр Татарстан ЮХИДИендә. Ә тимер машина белән килешеп булмый, ул очракълы саннар белән эш итә. Инде ул биргән номер кайберәүләрнең җеннәренә туры килми икән, яңадан пошлина түләп, бәхетеңне икенче кат сынап карарга мөмкин. Иске номерлары зур кыйммәткә ия кешеләргә аны саклап калу юллары бар, билгеле. Машинаны сатып, аны исәптән төшергәннән соң да номерлар тагын бер ай дәвамында иске хуҗаныкы булып кала бирә. Шул бер ай эчендә икенче машина алып өлгерсә, үз номерын калдыру турында гариза яза ала, диләр ЮХИДИ хезмәткәрләре.

... «дача амнистиясе»нә ышанам

Миңа мирас булып җир кишәрлеге калды. Биредә мин үземнең зур булмаган фермерлык предприятиемне оештырдым һәм йорт төзедем. Йортны үз милкем итеп ничек рәсмиләштерергә?

Булат Мирзануров, Буа

Бу сорауга ТР буенча Кадастрлар палатасы директоры урынбасары Ләйсән Гатауллина җавап бирә. Җирдән файдалану кагыйдәләре нигезендә анда фермалар булдыру, башка хуҗалык корылмалары төзү рөхсәт ителә. Ә бу биләмәдә торак йорт төзү башка мәсьәлә. Монда милеккә хокукны рәсмиләштерүнең җиңеләйтелгән вариантын кулланып булмый. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә башкачарак якын килергә кирәк. Әмма «дача амнистиясе» таләпләренә туры килә торган шартлар тудырырга. Алай эшләгәндә торакны шәхси милеккә күчерү өчен сезгә җир өчен хокукны булуыгызны раслаган документлар да җитәчәк. Бу юл әйләнеч, әмма ышанычлы. Кадастр инженерларыннан башка очына чыгып булмый, билгеле. Беренче эш итеп йорт биләгән урынны авыл хуҗалыгы өчен билгеләнгәненнән аерып межаларга кирәк. Бер участоктан икене ясаганлыгыгыз кадастрда чагылырга тиеш. Аларның һәрберсенә аерым номерлар биреләчәк. «Торак зона»га кадастр паспорты белән җирле үзидарәгә барыгыз. Муниципаль хакимият җирне бер төрдән икенчесенә күчерсеннәр өчен ходатайство бирергә хокуклы. Сезнең очракта – торак пунктлар төренә. Нәкъ менә шул төргә кергән җирләрдә генә торак йортлар төзергә ярый. Җирнең статусын үзгәртү турындагы карарны республиканың Министрлар Кабинеты кабул итә. Бераз көтәргә туры килер. Расладылармы? «Дача амнистиясе» шуннан соң гына көченә керә. Хәзер йортка бары тик кадастр паспорты гына кирәк. Җиргә хокуклы булуыгызны раслаучы документлар һәм тиешле гаризагызны тотып Росреестрга барырга гына кала.

Сәхифәне Илсөя ЗӘЙНУЛЛИНА әзерләде

Зифа Кадыйрова исеме бүген китап яратучы һәркемгә таныш. Ул профессиональ язучы түгел, сюжет-композиция төзелешендә әдәби нормалар искә алынмаган дигән сүзләр ишетелә тора, аның белән кемдер авыз чайкый икән – соенергә генә кирәк. Димәк, ул кемнеңдер кытыгын китерер дәрәҗәдә иҗат итә белә.

«Сагынырсың, мин булмам», «Көтеп узган гомер», «Язмыш сынавы» китапларының үз укучысын булдыруының сере үз эченә яралы язмышларны сыйдыруы белән бәйле. Шәхсән минем инде бик күптән аерыла алмыйча, төн йокысын калдырып китап укыганым юк иде. Минем бик күптән моның кадәр тетрәнгәнем, рухи чистарынуга этәргән әсәргә юлыкканым булмаган икән.

Зифа КАДЫЙРОВА:

«Минем көчем — көчсезлегемдә»

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Сыер именә ябышып үстем

– Нинди язучы булу турында хыяллану ди, башыма да кергәне булмады, – диде Зифа Кадыйрова «Шәһри Казан»га кунакка килгәч, аны каләмгә китергән иҗат юлы турында сөйләшеп утырганда. – Мәктәптән кайтышка сумканы болгап атам да фермага йөгерәм. Сыер именә ябышып үстем, киләчәгемне дә аннан башка күз алдыма китерми идем мин. Туган авылым Башкортстанның зур Ахун авылыннан башка ничек күзаллыйм ди мин киләчәкне? Терлек карармын, кияүгә чыгып балалар үстерермен дип уйлый идем. Шуңа укырга да яратмаганмындыр инде. Мәктәптә укыганда әти-әнине «биш»ләләр белән куандырмадым. Миңа тизрәк табигать кочагына чыгып китүләр, ялгызым калып, хыял киңлегендә очулар күпкә кадерлерәк иде. Әни сыек чыбык белән эзли чыкканчы, өйгә кайту юк. Дус табып, кем беләндер уйнаулар да миңа хас түгел иде. Уйный да белмәдем кебек мин. Минем дөнья – Ахунның урман-аланнары булгандыр. «Сагынырсың, мин булмам» әсәремдә дә мин шул туган авылым турында язам. Без үскәндә авыл искиткеч иде бит ул – бия савулар, елкы көтүе көтүләр. Шомырт өлгергән вакытларда шомыртның һәр ботагында бер бала утыра иде. Урам тулы кеше, капка төпләрендә дөнья хәлләре турында гәпләшү дисеңме... Ә хәзер? Моннан бер ел элек тау башына менеп утырган идем – авыл урамнарында кеше юк. Авылда ир заты күренми. Берәр борылмадан ат җиккән берәрсе килеп чыкмасмы дип күпме көтсәм дә, берәү дә күренмәде. Сугыштан соң да һәр йортта икешәр ир-ат булган, ә хәзер ирләргә кытлык...

– Ул вакытта кичләрен сукыр лампа каршысында китап укулар да үзе бер кадерле истәлек буларак саклангандыр?

– Китап укып үстем дип мактана алмыйм. Мин укырга яратмадым. Сигез чакрымны йөреп укый идем, шул араны техникага утырмаска, кешегә иярмичә генә тәпиләп кайтырга яраттым. Үзалдыма гына хыялланып кайта идем. 1978 елда Чаллыга килеп эләккәч тә китап белән дуслык булмады. Ә язасы килү теләге һаман озата барды. Каләм кешегә авыр чорда котылу чарасы икән ул. Яшьрәк чакта моны аңласам булсам, җиңелрәк тә булыр иде. Миңа исә 48 яшемдә генә кулыма каләм алырга туры килде...

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

Спонсорым — ике кулга бер көрәк

– Бишенчедә укыганда өй эше итеп инша биргәннәрен хәтерлим. Мин дә нәрсәдер язып алып килдем инде – аңа 5/2 куйдылар. Шуннан укытучы, менә бит, син дә булдыра аласың, дип, мине мактап, торгызып бастырды. Әллә нәрсә булды миңа – торып басуын бастым, әмма шуннан соң үз-үземә шым гына утырырга сүз бирдем.

Балалар тугач, иремә әллә нигә бер, язасы килә, дия башладым. Күңелне бушатасы килә иде. Мин бит соңгы ун елда ирләр арасында эшлим. Әмма эшемне һәрвакыт яраттым, әһәмият биреп эшләдем. Маляр булып эшли башлаганны хәтерлим, буяу исеннән исергәнмен, организм әлеге агулануга елау белән реакция кайтара – елый-елый автобуста кайтып киләм. Әмма бу эшне дә яратып башкарырга өйрәндем. Бу эшнең минеке түгел икәнен дә чамалыйм инде. Әмма кара эштән китәргә тырышу түгел иде ул. Мин хәзер дә китап басу өчен типография сораган акчаны шул кара эш белән шабаш эшләп җыям. Аның каралыгы мине оялтмый. Ә урамда калган вакытларны хәтерләгез сез. Бер тапкыр хезмәт хакын алты тәгәрмәчләтә бирделәр. Машина юк, көпчәк бар. Берсендә ике әрҗә аракылата бирделәр – аны кая куясың ди, кайгыдан эчеп бетерсәң генә. Ул яктан караганда авыр иде авырын. Әмма каләмгә тотынасы килү кешегә нидер күрсәтү, кеше укыту өчен түгел, үзем өчен булды. Шулай бер төнлә торып утырдым да өстәл янына килдем. Хат языйммы икән, дим? Үзеннән-үзе Сөмбел язмышы языла башлады. Иртән шаккаттым – үзем дә сизмәстән мин үз кулыма кеше язмышы алган булып чыктым. Сорау калкып чыкты – ничек бу кешене бәхетле итәргә? 540 битлек әлеге кульязманы башта күрше сорап торып укып чыкты, аннан китте-китте, соңрак караламамны көчкә табып алдым. Соңрак электромонтажник булып эшкә урнаштым. Шунда инструктаж узганда, багана башында янып үлгән ир-ат язмышы турында сөйләделәр. Икенче әсәремә тотындым.

– Моңарчы бит инде беренче китап үз укучысын эзләп тапкан иде?

– «Сагынырсың, мин булмам» китабын мин башта 100 данәдә генә чыгардым. Ул минем юбилейга килгән кунаклар, балалар өчен генә дип каралган иде. Аз санда булгач, аның хакы ат бәясенә төште. Юбилейдан соң ук аның Казан аръягына барып чыкканы ачыкланды. Китап сорый башладылар – мин китапны нинди бәягә чыкты, шул хакка куйдым. Китап кибетендә китаплар 20-30 сум тора. Минеке – 200 тәңкә. Алмаслар инде моны, дип кайтып киттем. Әмма хикмәти Хода, алар бер тында таралып бетте. Хәзер ун меңнән артык тираж белән чыгардым. Җитәрме, юкмы, белмим. «Сагынырсың, мин булмам»ны хәзер рус теленә тәрҗемә иттеләр.

– Ат бәясенә төшкән беренче китапны чыгаруда ярдәм итүчеләр табылмады инде?

– Беркемнең дә ярдәме булмады, бүген дә безне кредитлар яшәтә. Спонсорым – ике кулга бер көрәк, дип көләм. Әмма алай да башлаганда ярдәмсез үк булмады. Язмаларыма Айгөл Әхмәтгалиева алынмаса, «Мәйдан» журналында басылмаса, алар кеше арасына чыкмас иде. Журналда басылу реклама булды. Тик шулай да бер нәрсә эчне пошыра – интернет-кибетләр рөхсәтсез сату итә, район газеталары ничә ел рөхсәтсез бастырып кулланалар. Ә минем исә берәүгә дә ярдәм сорап барганым юк. Үзебезнең өстә – ирем белән бергәләп тырышабыз. Татарстанга да, Башкортстанга да китап нәшриятларына барып карадым үзе. Хатасы күп, дип җавап кайтардылар да кульязма тузан җыеп ятуын белде. Надан китаплар белән йөри, диючеләр табылды. Мин бүген дә Татарстан белән Башкортстан арасында эленеп торган язучы – тегеләр якка да кирәкми, бу якка да дигәндәй. Алай да «Сагынырсың, мин булмам» китабын быел башкорт теленә тәрҗемә иттеләр, быел аны «Агыйдел» журналы бастырырга җыена.

Мин кухнядан чыга алмыйм

– Балачакта китап укымавыгыз турында хөкем итеп булмый, хәзер исә үзегез дә каләм тибрәтүче кеше буларак, әдәбият белән кызыксынып барасыздыр бит?

– «Мәйдан», «Агыйдел» журналларын күзәтеп барам, Фәүзия Бәйрәмова кебек документаль жанрда эшләүче язучыларны укып барырга тырышам. Дөресен әйткәндә, башкаларны укымыйм. Яшь вакытта сырлап агач ясарга өйрәнгән хәтердә. Янәшәдә минем белән бергә ясаучыныкын күрдем дә аныкы матуррак тоелды. Нәтиҗәдә, аныкына охшатырга тырышкангамы, ул кешенеке дә барып чыкмады, минеке дә. Миңа әлеге сабак гомерлек булды.

– Маляр, кондуктор, ташчы, юлчы... Хәзер беренче урында иҗатмы инде?

– Иҗат минем өчен беренче урында тормый. Мин бит кухнядан чыга алмый торган зат. Аннан җаваплылык хисе дә чабудан тарта. Халык миннән әллә ни көтә – бирә алмам дигән курку яши. Әмма икенче яктан, тормышны күзәтү тәҗрибәсе бар, әйтер сүзләр күп. Хәзер менә нинди заманда яшибез без – ата-ана кадере китә бара, бәясе төшә. Балаларга көчебез җитми. Ә хатын-кызларыбыз нинди? Гараждан алып чыгып машинасын кабызып куя ул, бидон-бидон сөтен үзе төяи, чәче кыркылып киселгән. Өйдән озата чыгучы иренә, ашны пешереп куй, дип әмер бирә дә кузгалып китә. Тегеләр ир хуҗалыкта кирәкле берәр нәрсә сорап кергән күршесен: «Хатын кайткач, сорарсың», – дип борып чыгара. Ә безнең әбиләр нинди зирәк булган, әйеме? Ир өйдә булмаганда бусаганы чит ир-ат атлап та кермәгән, ирдән узып җавап бирү тыелган. Менә шул нәрсә җитми бүген хатын-кызга. Хатын-кызның бит көче – көчсезлегендә. Традицион гаилә нигезләре юкка чыга. Ә мин әсәрләремә матур үрнәкләр кертеп, матурлыкка өндәргә тырышам. Ирләр гаилә башлыгы булу вазифасын өсләреннән төшермәсен, хатыннар исә дилбегәгә үрелмәсен иде.

– Сез моны гомерегез буе ир-атлар арасында эшләүче хатын-кыз буларак та күзәтәсездер?

– Төрлесен күрәсең инде. Йөргән кызын «телка» дип атаучысын да, «иркәм» дип дәшүчесен дә күргән бар. Мин тискәре, колакка ятышсыз сүзләр ишетсәм, читкә китеп басам. Әмма тәгаен беләм – матур итеп дәшкәненең тормышы да матуррак, бәхете дә түгәрәгрәк була.

– Түгәрәк бәхет дигәннән, «Көтеп узган гомер»дәге онкология темасы, аның бәхетсезлеге Сезне дә урап узмаган дип беләм?

– Кагылды, мине дә урап узмады... Онкология белән күзгә-күз очрашкач, хатын-кыз иң элгәре нәрсә эшләп калдырырга кирәк, дип баш вата. Өеңне җыештыру булсынмы ул, балаларыңны тизрәк башлы-күзле итүме, иреңне кем кулына тапшырасы. Юк, көлке түгел, кайсы иптәш кызга калдырырга икән, дип уйлыйсың. Иреңнең кемгә калуыннан балаларыңның да киләчәге тора бит. Бу уйлар барысы да минем баштан узды.

– Укучылардан һәрвакытта мактау, рәхмәт сүзләре генә ишетәсезме?

– Төрлесе була. Әле менә күптән түгел генә бер үзешчән театрның минем «Сагынырсың, мин булмам» әсәре буенча сәхнәләштергән спектаклен карадым. Актерлар елый, зал елый, аларга карап, мин елыйм дигәндәй. Бер бушану, тугарылу димме... Килеп рәхмәт әйтүчеләр шактый булды. Бер кешенең: «Укый алмыйм мин аның китабын, авыр», – дигән сүзен дә ишеттем. Мин соендем – бу җирдә тормышта бернинди авырлык күрмәгән хет бер кеше булса да бар икән!.. Мәзәк хәлләр дә булгалый. Бер сиксәннең үр ягындагы әбекәй безнең уртак таныш аша: «Әйтегез әле шул Кадыйровага, мәхәббәт турындагы урыннарын тәфсилләбрәк язсын», – дип әйтеп җибәргән. Әбиләргә дә мәхәббәт җитми.

Ир хакы, бала хакы

– Хатын-кызга үзе теләгәне белән шөгыльләнсен өчен иң әүвәл ир фатихасы кирәк. Әдәби дөньядан моңарчы ерак яшәүче хатынының киңәттән генә каләмгә үрелүенә ирегез ничек карады, Зифа апа?

– Язасы килү теләгемне мин иң элек ирем Марсельгә әйттем. Ул, яз, диде. Улыбыз Руслан авариягә эләгеп, әни кеше өчен иң авыр вакытларның берсендә мин каләмгә тотындым. Ирем башта тавышсыз гына мине күзәтте. Әзер булгач, укырга дип, кульязманы аңа тоттырдым. Бу юлы читтән мин күзәтәм – бу башта кырын ятып укый, аннан торып йөренә башлый, аннан балконга тәмәке көйрәтергә чыгып китә. Укып тәмамлагач, миңа: «Яз, синең барып чыга», – диде ул. Марсель гомумән, бик белемле, киң эрудицияле кеше. Омар Хәйямнәр, Дәрдемәндләр иҗатына гашыйк. Шуңа да миңа зур терәк була белде, без очрашуларга да бергә йөрибез, китап бастыру проблемасы да уртак.

– Димәк, бергә узган еллар заяга узмаган?

– Тормышта уртак адымнар беркемнең дә, беркайчан да җай гына, рәхәт кенә бармый. Бик күп күз яшьләре аша яулап алынган иң төп аңлашуга кадәр гаилә әле ныклап тамыр җәйми дип исәплим мин. Безнең дә андый аңлашу булды. Инде хәзер икебезгә дә 54әр яшь. Шөкер, безнең иртәнгә кадәр сөйләшеп чыгарлык уртак сүзебез бар. Улыбыз Руслан, кызыбыз Регина да шул уртак бәхеткә керә.

– Зифа апа, әңгәмә ахырында, кайчан укучыларны яңа китап белән сөендерәсез, дигән сорауны бирми калдырсам, мине кичермәсләрдер...

– Киләсе ел ул минем юбилей елы. Шуңа да яраткан укучым китапсыз калмас дип уйлыйм. Әлегә исеме сер булып калсын.

Соңгы вакытларда телевизор экраннарында яки интернетта «Күз тиюдән коткарам, күз тиюдән сакланыр өчен бөтиләр ясыйм» дигән рекламалар ешайды. Күз тиюдән бөти коткара аламы, берниндн шарлатанга мөрәҗәгать итмичә генә күз тиюдән үзеңне үзең өшкереп буламы? Аның өчен нинди сүрәләр укырга кирәк? Әлеге сораулар белән без Казанның «Котдус» мәчете имам хатыйбы Рөстәм хәзрәт ВӘЛИУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.

Күз тию дөяне дә үтерә

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Дилбәр ГАРИФ

– Рөстәм хәзрәт, нинди кешегә күз тиючән була?

– Кешегә күз тию дигәнне аның матурлыгына, байлыгына, булдыклылыгына һәм башка шундый күзгә бәрелеп торган сыйфатларына күз тию дип аңларга кирәк. Шулай ук аның мал-мөлкәтенә дә күз тияргә бик мөмкин. Расүлебез (с.г.в.) аның хак икәнлеген әйткән, ягъни, күз тию – хак, дигән. Шуңа без күз тиюнең барлыгына ышанабыз.

– Кеше үзенә күз тигәнне сизәме?

– Сизәргә мөмкин. Арыганлык, сүлпәнлек сизелү, гел йокымсырау, Коръән һәм намаз укыганда иснәнү, Коръән укырга теләк булмауны күз тиюнең билгеләре дип карарга кирәк.

– Кеше үз-үзен өшкерә аламы? Күз тиюдән нинди дога укырга кирәк?

– Әлбәттә. Ул Пәйгамбәребез (с.г.в.) тарафыннан да әйтеп калдырылган. Кеше үз-үзен Коръән-Кәримдәге аятьләр белән өшкерә ала. «Бисмиллаһ» әйтеп тәһарәт аласың да кулыңны күтәреп, учыңа белгән сүрәләреңне укыйсың һәм тәнеңне сыпырасың. Күз тиюдән аеруча файдалы сүрәләр – «Фәләкъ» һәм «Нәс» сүрәсе.

– Күз тиюдән саклану өчен булавка кадап куючылар, миләш бөтиләр тагып йөрүчеләр бар. Балага, күз тимәсенгә, ике каш арасына иннек тә сөртеп куялар, болар чынлыкта да саклыймы?

– Аларның көче юк. Кеше моның файдасы бар, ул мине саклый дип ышанса, бу – гөнаһ, ырымга ышану дигән сүз. Безне бары тик Аллаһы Тәгалә генә саклый. Ә менә аларны тагып йөрү тыелмый. Әйтүләренчә, кешенең ни элек күзе шуңа төшә. Үзен күз тиюдән саклар өчен Расүлебез (с.г.в.) дә күзгә бәрелеп тора торган ачык төстәге кием кия торган булган бит.

– Кечкенә балаларга бигрәк тә күз тиючән була...

– Мин, гадәттә, бала өстенә дүрт тапкыр «Фатиха» сүрәсен, дүрт тапкыр «Аятел-көрси»не, аннан «Ихлас», «Фәләкъ» һәм «Нәс» сүрәләрен кычкырып укыйм.

– Рөстәм хәзрәт, ә нинди кешенең күзе тия?

– Күз тию ул – каршылыклы мәсьәлә. Бик ихлас, яки, киресенчә, бик тә кара эчле кешенең күзе тиючән. Ихлас кеше, чын күңелдән сокланып, «сөбханалла»сын әйтергә онытып, кеше өстенә нәрсә дә әйтсә, аның күзе тияргә мөмкин. Андыйларга һәрдаим «сөбханалла» дип әйтергә, шул сүзне әйтүне гадәткә кертергә кирәк. Бар кара эчле, көнче кешеләр. Алар, үзләренең күз көче тәэсирен белеп, максатчан күз тидерергә дә мөмкиннәр. Болары инде тәүбәгә килергә тиеш. Югыйсә ул моның өчен барыбер җәзасын алачак. Аллаһы Тәгалә, сихер белән шөгыльләнүчеләрнеке кебек, аның үлем мизгелен авырайта.

Бар кара эчле, көнче кешеләр. Алар, үзләренең күз көче тәэсирен белеп, максатчан күз тидерергә дә мөмкиннәр. Болары инде тәүбәгә килергә тиеш. Югыйсә ул моның өчен барыбер җәзасын алачак

– Күз тиюдән коткарам дип, үзләрен рекламалаучылар бар. Аларга ышаныргамы?

– Аларга ышанырга кирәкми. Бу бизнес кына. Иң яхшысы, әйткәнемчә, белгән сүрәләреңне укып, үз-үзеңне өшкерү. Ярдәм итми дисәгез, үзеңнән ихласрак, тәкъварак, намазлы, ихлас күңелле, уразалы кешене табып, аның укуын үтенегез.

– Күз тиюдән сакланып буламы?

– Әгәр дә үз тирәндәге берәүнең күзе төшүчән икәнен белсәң, аны «Сөбханалла»ны әйт дип кисәтергә курыкмагыз. Аллаһы Тәгаләгә: «Йа Раббым, күзе тиюдән сакла», – дип ялварырга кирәк. Булган әйберләрегез, мал-мөлкәтегез турында сөйләп мактанмагыз, чөнки көнче кешегә син мактанган саен авыр. Күз тиюгә җиңелчә генә карарга кирәкми, ул бик җитди нәрсә. Ниндидер бер вакыйга уңаеннан Пәйгамбәребез (с.г.в.), бер-берегезгә күз тидерүдән, күз тидереп бер-берегезне үтерүдән сак булыгыз, дигән. Күз тию аркасында кайберәүләр бөтенләй авыруга сабышырга мөмкин. Күз тигән кеше, хәле авыр булгач, табибларга барырга, ә табиблар авыруның сәбәбен таба алмаска мөмкин. Анализлары да яхшы кебек. Тик ул теге яки бу җирем авырта дип зарлана. Аның сәбәбе шул күз тию яки сихер булуы бар.

Иманы булса — кайтарыр...

БАШЫ 3 НЧЕ БИТТӘ

Югыйсә журналист кешенең игътибары, күзәтүчәнлеге бермә-бер артык булырга тиеш бит... Исерек булсам, бер хәл, аек көе «исереп» йөрү тагы да яман икән..

Нишләргә? Букчада калган телефоныма шалтыратырга керештек. Тик күпме шалтыратсак та, телефонны алучы булмады, соңрак телефон сүнеп үк китте. Машина маңгаендагы сары шашкага язылган номерны искә төшерергә керештек һәм «анда икеле һәм берле саннары язылган иде» дигән уртак фикергә килеп, телефон аша белешмәләр хезмәтенә мөрәҗәгать иттек. Такси диспетчерларының әлеге саннарны үз эченә алган дүрт-бишләп кайнар элемтә линиясе барлыгын ачыкладык. Баксаң, Казан буенча диспетчерлар аша эш итүче алты меңнән артык машина хуҗасы бар икән. Менә сәлам эскерте арасына төшкән энәне эзлә син. 6 мең машинаның ничәсе көмешсу төстә дә, ничәсе 11ле маркалы «ВАЗ» икән?! Бу төнне күзгә йокы кермәде. Башымда, әллә соң иртәгә «Эфир»дагы «Город» тапшыруы аша мөрәҗәгать ясыйммы икән, дигән уйлар да бөтерелде. Икенче яктан, туганнарым, якын кешеләремә бу мәгълүматны җиткерәсем, аларны борчыйсым килмәде. Әгәр такси хуҗасы мөлкәтне кайтармаска уйласа? Әгәр берәр башка пассажир сумканы эләктереп чыкса? Әгәр... Күз карасыдай саклый торган әйберләремне ничек шулай онытып калдырырга була инде! Оят бит, оят!

Файдасы тияренә ышанмасак та, Эсперантода урнашкан 8нче санлы полиция участогына юл тоттык. Тик, үз гаебең белән югалткач, ни дип язасың инде: «Прошу уголовное дело не возбуждать, оставил по своей неосторожности...» Моннан да мәгънәсезрәк хәл, моннан да мәгънәсезрәк аңлатма булырга мөмкинме икән?! Юктыр, мөгаен. Нишләтәсең, кирәк чагында киңәшерлек юрист иптәш тә янәшәдә булмый бит. «Эзләтергә» дигән карар чыгарып кына югалган әйбер табылса икән ул. Җитмәсә, алда бәйрәм кичәләре, яңа ел каникуллары...

Икенче көнне безнең эштә дә яңа ел корпоративы иде, тик бәйрәм кәефе генә качты. Шулай да эчке халәтемне йөземә чыгармаска тырыштым. Баксаң, «ШК»ны Рафаэль Ильясов гаиләсе генә түгел, ә «Юкка түгелдер» дип җыр сузучы Вил Усманов гаиләсе дә укый икән («ШК» редакциясе коллективын Яңа ел белән котларга килүчеләр арасында ул да бар иде.). Әйе, һәр нәрсәнең яхшы ягын күрергә, тормыштагы һәр вакыйгадан сабак алырга өйрәнергә кирәк шул. Бер генә нәрсә дә юкка түгел. Адәм баласы бер тукталып уйлансын, нәтиҗәләр ясасын өчен тетрәнүләр дә кирәк. Эшкә баргач та, коллектив әгъзалары: «Адәм башы түгел ич! Аллага тапшыр! Насыйп булса – табылыр! Иманлы бәндә булса – кайтарыр!» – дип, яхшыга юрарга киңәш иттеләр. Баш мөхәррирнең: «Ноутбуксыз йөри алмыйсың бит инде, булышырбыз!» – дигән сүзләре дә күңелне җылытып җибәрде. Ә бәйрәм кичәбез тәмамланыр алдыннан телефоным шалтырады: «Здравствуйте! Это Фаниль Гилязов? Вы вчера ничего не потеряли? Мне чужого не надо». Кинәт дөньялар яктырып китте. Бу – кичәге такси хуҗасының тавышы иде. Шулай итеп, җомга кичендә Яңа ел алдыннан могҗиза көтәргә мәҗбүр булган күңелемнең өметләре акланды. Күрәсең, Николай иманлы бәндә булып чыкты. Хәер, могҗизаны яңа ел төнендә сәгать сукканын көтеп, бокаллар күтәреп түгел, ә бәлки һәр нәрсәнең сәбәпчесе булучы, тәкъдир сынауларын бирүче Аллаһ Раббыбыздан кулларны күтәреп, һәр җомга намазы саен мәчеткә барып сорау дөресрәк булыр. Алда иске календарь буенча Яңа ел җитә. Ә Аллаһ Тәгалә ул төнне генә түгел, һәр төнне, һәр көнне аңа мөрәҗәгать итүчеләрнең хәерле догасын кабул итә.

Гыйнварда намаз вакытлары

	Иртәнге намаз	Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
14	07:34	09:04	13:02	14:52	16:41	18:11
15	07:33	09:03	13:02	14:55	16:43	18:13
16	07:32	09:02	13:02	14:55	16:44	18:14
17	07:31	09:01	13:02	14:57	16:46	18:16
18	07:29	08:59	13:02	14:59	16:48	18:18
19	07:28	08:58	13:02	15:01	16:50	18:20
20	07:27	08:57	13:02	15:02	16:52	18:22
21	07:25	08:55	13:02	15:04	16:54	18:24
22	07:24	08:54	13:02	15:06	16:56	18:26
23	07:22	08:52	13:02	15:08	16:58	18:28
24	07:21	08:51	13:02	15:10	17:00	18:30

Матур гаилә — илнең матурлыгы

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

БӘДРЕТДИНОВлар, **КОРБАНГАЛИЕВ**лар гаиләсе, Балык Бистәсе

Аллага шөкер, балаларыбыз балигъ булып үсеп җиттеләр. Улыбыз Алмаз армия хезмәтен үтәп, һөнәр алып, Казанда эшкә урнашты. Сөйгән кызы Рания – шәһре Болгар каласыннан. Уйлашып, киңәшеп аларны шәригать кушканча өйләнештерергә, никах укытып, төп нигездә хәләл туй мәҗлесе үткәрергә ниятләдек. Өлкән күршебез Халит абый: «Ширияздан абыеңнан укытыгыз. Ул гыйлемле кеше. Барысын да шәригать кушканча башкарыр», – диде.

Никах көненә төп нигезгә барча туганнар парлашып килделәр, якын күршеләр дә җыелды. Болгар җиреннән ерак араларны якын итеп кәләшнең туганнары килеп җиттеләр. Өстәл артына утырышкач, Нух пәйгамбәр догасын укып дога кылдык, хәл-әхвәл белештек. Табыныбызда үзебез әзерләгән хәләл ризыклар, күчтәнәчләр мулдан иде.

Мәҗлес салават әйтеп, Коръән укып, әрвахларның рухына дога кылып башланды. Ширияздан абый никахның һәр фасылын, әҗер-савапларын Аллаһы Тәгалә тарафыннан адәм балаларына йөкләтелгән фарыз, изге вазифа икәнен, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)-нең сөннәте икәнен Коръән китабын ачып сүрә-аятьләрен укып, хәдисләр китабыннан дәлилләр китереп, яшьләрнең күңелләренә сеңдерлек итеп аңлатты. Егет белән кыз шаһитлар алдында, иман кәлимәсен әйтеп, гомерләре буе ир-хатын булып яшәргә вәгъдә бирешеп, ризалыкларын белдерделәр. Аларны тәбрикләп район имам-мөхтәсибе Сәүдахан хәзрәтнең имзасы һәм мөһере куелган Диния нәзарәтенең «Никахлашу Шаһәдәтнамәсе» тапшырылды. Ширияздан абый яшь парларга бүләк-нәсыйхәт итеп Хаҗдан кайткан намазлык, дисбеләр, Коръәннең татарча тәфсире, Татарстан мөселманнарының баш казые Җәлил хәзрәтнең «Иманлы бала» китабын тапшырды. Өйлә намазы җиткәч намаз укуның һәр мөселманга фарыз икәнен аңлатты. Намаз уку тәртибен рәсемле ярдәмлекләр күрсәтеп өйрәтте (әүвәлге заманнарда һәр татар-мөселман баласы яшьтән үк намаз укый белгәч, никах мәҗлесендә болай аңлату кирәк тә булмагандыр, бәлки). Безнең балалар өчен бик файдалы сабак булды бу.

Мәдәни ГАВАМ

Сәхнәгә 60 ел гомерен багышлаган Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рауза ХӘЙРЕТДИНОВА шушы көннәрдә үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Шушы дәвердә артист җан өргән образларны санап бетерерлек түгел. Аның «Галиябану» спектаклендә – Галиябану, «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә, «Гүзәлем Әсәл»дә – Хәдичә, «Татар хатыны ниләр күрми»дә – Гөлбану һ.б. рольләренең һәркайсы тамашачы күңеленә кереп калды. Сәхнәдәше Татарстанның халык артисты, якташы Хәлим Җәләлов Рауза апа хакында: «Ул чишмәдәй челтерәп торган матур тавышлы, чибәр артист иде. Сәхнәдә бик таләпчән булды. Шаярганны кабул итмәде, эшенә һәрвакыт җитди карады», – дип сөйли.

«ТОРМЫШЫМ КӨРӘШЛӘРДӘН торды»

ЮБИЛЕЙ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Рауза апаның моңлы тавышын безнең буынга да ишетү насыйп булды. Хәсрәт йотып үскәннәрнең генә йөрәгенә шундый моң тула торгандыр ул. Моңсу балачагы калган туган ягында бүген дә үзенә кадер-хөрмәт күрсәтүләренә чиксез куана артист. Югары Ырга мәктәбендә Рауза Хәйретдиновага багышланган музей оештырганнар. Танылган шәхес өчен бу иң зур бүләк.

«85 яшьтә үзегезне ничек хис итәсез?» – дигән соравыма артист: «85 саның ишетү миңа бик сәер тоела. Йөрәк әле һаман яшь килеш. Мин беркайчан да яшемне санамадым. Бүген «әби» дип дәшкәннәренә дә ияләшә алмыйм», – дип җавап кайтарды.

– Рауза апа, Сезнең гомер юлы көрәшләрдән торган сыман. Тормышыгызда иң зур җиңү нәрсә булды?

– Әйе, ул көрәш минем бала чагымнан ук башланды. Балык Бистәсе районының Югары Ырга авылында яшәгәндә, миңа ундүрт яшь тулганчы, әниебез гүр иясе булды. Әти фронтта. Ике баланы тәрбияләү минем җилкәгә төште. Урманнан иңбашыма күтәреп печән, утын ташуларымны һич онытасым юк. Шуларны искә алсам, әле дә күзләрем яшькә төренә. Әнидән калганда токмач кына кисә белә идем. Энем белән сеңлемә урын-җир җәймәсеннән күлмәкләр тегеп кидердем. Өч ятим дип тормадылар, әйберләребезне урлап чыккан чаклары да булды. Ул вакытларда безне туендырган сыерыбызны саклап калу өчен күпме көч түгүемне бер үзем генә беләм. Өебез тәрәзәсеннән күренеп торган зиратка карап, үрсәләнеп елауларыбыз аз булмады. Әнә шулай ниндәй авырлыклар күреп тә, әтиебез кайтканчы, туганнарымны балалар йортына бирмичә, саклап калуым минем иң зур җиңүем дими ни дисең? Гомумән, минем тормыш гел көрәшләрдән торды.

– Тормыш йөген тарткан авыр балачагыгызда хыялланып та яши белгәнсез. Артист булу теләге дә мәктәп елларында ук уянган түгелме әле?

– Әти-әниебез укытучы булгангамы, аларга карап кечкенәдән укырга ярата идем. Өебездә китаплар күп булды. Анналары рәсем ясарга һәвәс булдым. Журналларда артистларның фотоларына карап, аларның портретларын ясый торган идем. Мәктәптә «Үги кыз» әкиятендә уйнаганнан соң, артист булу турында хыялланып йөри башладым. Алдагы көнемдә үземнең дә үги бала булып каласымны кем уйлаган ул чакларда.

– Сез бит әле ул елларда үзлегегездән балалайкада, гармунда уйнарга өйрәнеп, авылдашларыгызның күңелен күтәргәнсез.

– Чыннан да, гармун тавышы күп хатын-кызларны моңландырды ул елларда, чонки күбесенең ирләре фронтта иде. Шулай да бәйрәмнәрдә гармунда уйнап, аларның күңелләрен күтәрә идем. Ходай тарафыннан бирелгән моң миңа тормышта зур ярдәм итте. Заманында Салих Сәйдәшев нота да өйрәтә башлаган иде, үзем кызыксынмадым. Сәхнәдә җырлы рольләр уйнап, тамашачы мәхәббәтен яулаганмын икән, бу минем өчен зур бәхет.

– Сез күп кенә драматургларның әсәрләрендә уйнагансыз. Үзегезнең иҗатка бигрәк тә кайсы драматургның йогынтысы күбрәк булды, дип уйлыйсыз?

– Миңа дан-шөһрәт китергән драматург Кәрим Тинчурин. «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә минем иҗатымда аерым урын алып тора. Беренче мәртәбә Булатны Кәрим абый үзе уйнаган. Аның турында кызыклы истәлекләр дә сөйлиләр иде. К.Тинчурин әсәрен театрга алып килүгә, артистларга рольләрен үзе бүлә торган була. Баш рольне кемгә бирер дип көтсәләр, соңыннан: «Бу рольне үзем уйнармын инде», – дип куя икән.

– Сез сөйләшкәндә үзегездән өлкәнрәк артистларны да телдән төшермисез. Арада аеруча еш искә ала торганнары...

– Минем иҗат юлымда мәрхәмәтле кешеләр күп очрады. Хәким Сәлимҗанов, Галия Нигъмәтуллина, Гөлсем Камская кебек артистлар белән бергә Зифа Басыйрованы еш искә төшерәм. Гастрольләргә баргач, без аның белән бергә фатирга керә идек. Туры сүзле иде. Шуның аркасында театрдан да китте. Ул бүләк иткән ридикюльне мин гомер буе сакладым. Шулай ук күренекле артист Галия Булатованың илле яшьлек юбилеемда бүләк иткән муенсасына карап аны хәтердә яңартам. Бүгенге яшьләрнең дә өлкәннәрне онытмауларын телә идем. Рус артистлары турында телевидениедән тапшырулар карыйм да, авыр тормышта яшәп дөнья куйган актерларны җәллим. Шөкер, безнең театрда җиткәчеләр өлкән буынга һәрвакыт хөрмәт белән карады.

– Өлешенә тигән көмешең дигәндәй, артист режиссер биргән һәр рольне көтеп алганын беләбез...

– Бервакыт Шириздан Сарымсаков миңа Г.Әпсәләмовның «Хәерле юл» спектаклендә Идмас ролен биргән иде. Кырыс холыклы, бозык хатын дип аннан баш тарткан идем. Аннары режиссер барыбер күндерде үземне.

– Рауза апа, Сез театрда булган премьераларны да һәрвакыт карап барырга тырышасыз. Элек язылган әсәрләрне үзгәртеп куюлары белән килешәсезме?

– Театрга килеп керүгә, минем бөтен авыруларым онытылып китә. Шуңа күрә, сирәк кенә булса да, анда барырга тырышам. Яңа куелган спектакльләрне карыйсы килә. Әгәр үз әсәрләрен үзгәртеп куйганны күрсәләр, аларның авторлары да риза булмас иде. Әнә Фәрит Бикчәнтәев «Зәңгәр шәл»не бүген дә ничек язылган, шулай сәхнәләштергән. Халык яратып карый бит.

– Заманында ул спектакльдә уйнаган артистка шундагы берәр рольне уйнарга кушсалар, бүген кайсын сайлар идегез?

– Мин өлкән яшьтә булсам да, карчыкларны уйный алмыйм. Шулай да абыстайларның өлкәнрәген уйнап булыр иде. «Зифа»дагы Кәләмзәне дә уйнарга мөмкин.

– Гадәттә, һәр артистның тормышта үкенечле мизгелләре була...

– Аллага шөкер, минем үкенечем юк. Үзем яраткан рольләрне уйнадым, яраткан кешем белән яшәдем. Быел Нури абыегыз белән кавышуыбызга да 60 ел тула. Ул гомер буе көнләшүне белмәде. Шуңа да мин аңа рәхмәтле. Улыбыз Марат та быел үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. Безнең гаиләдә быел юбилейлар елы дисәң дә була.

ЯҢАЛЫКЛАР

«Язмышым юллары»

К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында Разил Вәлиевнең Резедә Сәлахова инсценировкасы буенча куелган «Язмышым юллары» шигъри-музыкаль спектакленең премьерасы булды.

Шагыйрь иҗатын төрле яклап колачлаган артистлар Артем Пискунов, Зөлфәт Закиров, Тимур Бәһаветдинов, Резедә Сәлахова, Лия Вильданова, Гөлназ Нәүмәтова, Булат Зиннәтуллин, Илфак Хафизов һәм Айгөл Галиуллина тамашачы белән ике арада иң кадерле һәм иң якын әйберләр турында гәпләшерләк ихлас мохит тудыра.

«Язмышым юллары» спектакле каһарманнары, нәкъ безнең кебек үк, үз бәхетләрен эзләүчеләр... һәм алар язмыш белән йөзгә-йөз очрашып, шатланып һәм борчылып, өметсезләнеп һәм хафаланып, әкрен генә гомер йомгагын сүтәләр, һәр кешенең язмышы үзе бер романга тиң. Бары өмет кенә үзләренә, төрле сынауларга бирешмичә, гомер юлыннан ахыргача үтәргә көч бирә. Чөнки ул безнең һәрберебезнең дә күңелендә яши.

Спектакльнең режиссеры Рәшит Заһидуллин, төрле стильләрне, сәнгатьнең төрле чикләрен бергә кушып, кешенең эчке дөньясы пәрдәсенең бер читен күтәреп, аның күңелендә ниләр булуын, безнең нәрсә ул Яхшылык һәм Яманлык сорауларына ничек җавап бирүебезне, ничек бәхеткә ирешүебезне күрсәтә. Спектакльдә Разил Вәлиев сүзләренә язылган берсеннән-берсе мәгънәле җырлар да яңгырады.

Экраннарда тагын бер якташыбыз

Гыйнвар аенда Россия кинотеатрларында «Продавец игрушек» фильмы күрсәтелә башлый. Анда баш рольне якташыбыз Шамил Хамматов башкара. Ул – танылган кино артисты Чулпан Хамматованың бертуган энесе. Ш.Хамматов Россия театр сәнгате академиясен тәмамлаган. Хәзерге вакытта «Современник» театрында эшли. Аңа 27 яшь. Фильмнарда да уйный. Әмма аңа театрда уйнау күбрәк ошый. «Продавец игрушек» фильмында ул дөнья күләмендә танылган француз киносы йолдызы Пьер Ришар белән бергә уйный. Шамил үзенең һөнәрен апасы ярдәмендә сайлавын яшерми. Шуңа күрә ул аның киңәшләрен тота. Җәй айларында алар әти-әниләренең Казан янындагы бакчаларында бергәләп ял итәргә яраталар.

НИ ХӘЛЕГЕЗ БАР?

Нуретдин НӘҖМИЕВ, Татарстанның халык артисты:

– Яңа ел алдыннан балалар өчен әкиятләрдә уйнадым. Ял итмичә эшләргә туры килде. Онытылбыз белән кичләрен чыршы бәйрәмнәренә йөрдек. Кухнябызда ремонт ясап алдык.

Мәсгут ИМАШЕВ, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре:

– Ноябрь аенда хатыным Фатыйма белән үземнең туган якларга кайтып, мәктәпләрдә осталык дәресләре үткәреп килгән идек. Үзебезнең Каенавыл мәктәбе минем исемне йөрткәнгәме, һаман чакырып торалар. Февральдә тагын чакыру бар. Яңа елдан соң туганыбызның туена кайтып килдек.

Инсаф АБДУЛЛА, Татарстанның атказанган артисты:

– Яңа ел алдыннан Башкортстанда яшәгән әниемне соңгы юлга озатып кайттым. Театр училищесында имтиханнар алдым. Үзебезнең улыбыз Айрат Казаньгә тел өйрәнергә китте.

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде

«Татарлар искиткеч талантлы»

Шулай булмый ни – Мәскәү тиклем Мәскәүдә дәрәҗәле конкурста берьюлы ике татар кызы, Татарстан кызы җиңеп чыксын да, безгә тагын уртакул булырга! Берничә ай дәвамында барган «Голос» конкурсының финалына 4 катнашучы чыгуын, шуның икесе үзебезнең кыз булуын белгәч тә күкрәк читлегенә төртә башлаган иде ул горурлык. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә кызларның үзләрен күреп сөйләшкәч исә «Афәрин!» дип кайттым мин. Булса да булыр икән шуның кадәр тотнаклы, фикерле, тыйнак, чын татар кызлары эстрада дөньясында. Татарның начар сыйфаты – хөсетлекнең тамчысы да юк бит үзләрендә. Инде беренчелеккә чыккан Динәсе булса да чак кына, мин җиңдем, миндә беренче урын, дип масаер дисең – юк. Без җиңдек, без тырыштык, без икебез – бер, дип сөйләшеп утыралар. Үзләре матур, үзләре сөйкемле, үзләре талантлы. Эчке культуралары, белемле булулары, тәрбиялелекләренә күз генә тимәсен!..

ЙОЛДЫЗЛЫ ЮЛ

Гөлнара ЖӘЛИЛОВА

Икесен тиң күреп, көч биреп утырсак та, Эльмира Кәлимуллинаның рус сәхнәсендә татар җыры алып чыгуы бөтенләй йөрәккә сары май булып япты шул. Пелагея белән берлектә «Син сазыны уйнадың» җырын башкаруы гына ни тора! Конференция барышында да нәкъ менә Эльмира ассызыклап үтәргә онытмады: «Татарлар искиткеч талантлы миллә». Динә исә кечкенәдән «Голос»та үзенең укытучысы булган Александр Градский иҗатына гашыйк булып үскән икән. Мәскәүдә шундый дәрәҗәдәге конкурс узуын белгәч тә, нәкъ менә Градский исеме хәлиткеч роль уйнаган кызга. Бәхетнең из зуры булып Градскийның аны үз төркеменә алуы булгандыр. «Сайлап алган 12 катнашучы – без бөтенебез дә Градскийның балаларына әверелдек, – ди Динә. – Бөтенебезгә дә ачкыч ярата белде. Аны бик кырыс, диләр иде. Кырыс ул, әмма бик кешелекле. Миңа исә яңа исем дә такты: «Олавянный солдатик».

Тотнаклылык ягыннан Эльмираны да Пелагея бик яраткан икән: «Кайда синдә хис-тойгылар, кайда кайнарлык? Эх, миңа синең сабырлыгың...» – дип көлдертә иде, ди кыз укытучысын искә алып.

Кызларның вокал мөмкинлекләре гади тамашачыны да таң калдыра алды. Ә заманында Эльмираны музыка училищесына, «тавышың юк», дип, алмый да калдырган булганнар. Музыка мәктәбен тәмамлаган, быел 24 яшен тутырачак кыз шуңа да башта юридик лицейда, соңрак шунда ук икътисад факультетында белем алган. Дуслары киңәше белән генә Казан дәүләт консерваториясенә барып карый ул. «Минем тавышыма үзбәям бик түбән иде, – дип искә ала Эльмира ул елларны. – Консерваториядәге укытучым Гөлнара Мурзиева миндә ул ышанычны булдырды. Ә мин аның ышанычын шушы конкурста икенче урынны алуым белән аклый алдым».

Динә Гарипова исә 1991 елның 25 мартында Яшел Үзән шәһәрендә туган кыз. Кечкенәдән җырмоңга тартылган яшь талант шәһәрдәге «Золотой микрофон» җыр театрына йөргән. Читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлап йөри ул хәзер. Аны Татарстан тамашачысы Габделфәт Сафин концертларында да күргәне бар иде.

Кызлар икесе дә «Голос» конкурсында узган чорларын «Чиксез бәхет» дип искә ала. «Без Татарстаннан, шундый зур конкурста республикабызның йөзе икәнебезне онытмадык, – диләр алар. – Бөтен Россия тавыш биреп караган әлеге чараның кыенлыгын күрмәдек. Эшләп ял иттек, ял итеп эшләдек дисәк тә була». Ә шулай да талант белән генә җиңеп чыгып булмый, дип исәпли икән кызлар, талант янына 99 процент тырышлык та өстәргә кирәк.

Минем: «Үзебездәге татар сәхнәсенә күтәрелү дә җиңелләрдән түгел, сез Мәскәү кадәр Мәскәүне «җиңдегез». Үҗәтлекме бу, фортунамы?» – дигән соравыма кызларның җавабы кызыклы иде:

– Татар эстрадасын тыңларга яратмыйм дисәм дә була, – диде Эльмира. – Илһам Шакировлар, Әлфия Афзаловалар турында сүз бармый, әлбәттә. Бүгенге шоу-бизнес, бүгенге татар телле җырларда бит хәзер моң дигән нәрсә калмады. Татар сәхнәсенә күтәрелү Мәскәүне яулаудан кыенрак. Чөнки бездә «әнә теге җирән чәчлесе ошый», «менә бу борчаклы күлмәк шәп» дигән критерийлар яши. Ә Мәскәүдә ул яктан андый тар кысалар юк. Әлеге конкурста да синең йөзеңә, кыяфәтеңә карамадылар. Анда тавышка карадылар. Ә профессионал кеше тавыштан бөтен эчке дөньяны чамалый ала – кем син, ни алып килгәнсең, интеллектың нинди, рухи тәрбияң... Мин, шәхсән, Мәскәүне яулыйм, дип махсус берни дә эшләмәдем. Нәрсә эшли алам – шуны гына эшләдем.

– Татарстаннан килгән рухи ярдәм үз эшен эшләгәндер дим, – дип шәрехләде Динә дә. – Минем соцчелтәрдәге битемә язган рухландыручы сүзләр генә дә ни тора! Бик зур рәхмәт якташларга! 29ы көнне Казан урамнары тынып калып, гомер телевизор карамаган кешеләрнең безнең өчен тавыш, көч биреп зәңгәр экраннарга берегүе генә күп нәрсә турында сөйли. Ә көч биреп утырганда таулар да күчерерсең...

– Хәзер халык очсыз тапшырулардан туйган. Телевизордан карарлык нәрсә калмады бит. Ә «Голос»ны карадылар. Димәк, безнең халык культурага сусаган, дигән сүз, – ди Эльмира.

Татарстанның атказанган артистлары исемнәрен алган кызларның башка фикерләре дә кызыклы иде. Динәгә, конкурсның абсолют батыры буларак, «Юниверсал» дөньякүләм танылган тавыш язуы студиясе белән килешүне карау, раслау көтсә, Эльмира өздереп кенә, нинди компания белән хезмәттәшлек итәсен ачыкламады. Хәер, кызлар әлегә ялда – алар Яңа ел төнендә генә Татарстан җиренә кайтып төште. Эльмирага шулай ук Университетның вәкиле булу бәхете дә елмайды. Без исә аларга хыялларының чынга ашып, яңа альбомнар яздырып, дөньякүләм танылуларын теләп калыйк. Иң мөһиме – кайда гына, кем генә булмасыннар, «без менә шундый милләт!» дигән горурлык очкыннары гына юкка чыкмасын иде аларда.

МӘСКӘҮЛӘРДӘН СӘЛАМ

Абрамович кабат әти була!

Кариб утрауларының берсе – Сент-Барт безгә тагын бер яңалык ачарга өлгерде. Олигарх **Роман Абрамович**ның сөйгәне – дизайнер **Даша Жукова** кабат көмәнле икән. Аның тәс-кыяфәтенә караганда, пар икеөч айдан икенче тапкыр уртак бала сөячәк. Беренче балалары Аарон-Александр 2009 елның 5 декабрендә дөньяга аваз салган иде. Аарон – борыңгы дини исем, әлеге исемне Дашаның әтисе рухына багышлап кушкан булганнар. Аарон-Александр Лос-Анджелесның «Седар Синаи» клиникасында туган иде. Ул вакытта бәхетле әти дөньяның берничә шәһәрендә урын арендалап куйган булган. Даша исә Бритни Спирс кебек үк Лос-Анджелесның данлыклы шәхси клиникасына туктаган иде.

Исегезгә төшереп китсәк, Даша Жукова белән уртак баладан кала, Абрамовичның Анна, Софья, Арина исемле кызлары, Аркадий һәм Илья исемле уллары бар.

Яна Рудковская малай тапты

Гыйнвар башында ире **Евгений Плющенко**ны бәхетле итеп, продюсер **Яна Рудковская** 2800 граммлы малай тапты. «Егет»кә Александр дип исем бирделәр. 38 яшьлек Янаның бу беренче генә баласы түгел – аның беренче никахыннан ике улы үсеп килә (дөрес, аларның берсенә ул биологик яктан әни түгел). 30 яшьлек Плющенконың да беренче никахтан туган Егор исемле улы бар. Мәскәүнең шәхси клиникасында туган улы Александр шатлыгыннан бәхетле әтинең интернетта рәхмәт сүзләре дә бар: «Улымны кулымда тотып торам. Бу бәхет өчен Ходайга һәм Яночкама зур рәхмәт!»

Искә төшсә үткәннәр...

«Рождественские встречи» тапшыруында кызык һәм кызганыч мизгел килеп туган икән. Әлеге кичәнең бер эпизодында **Алла Борисовна** иренә тугрылыклы булмаган хатынны уйный. «Зу-зу» җырын яздырганда килеп туган хәл түбәндәгедән гыйбарәт. Берьюлы ике иратны яратучы хатын-кызга кайчан да булса сайлап алу дигән катлаулы карарга килергә туры килә. Сценарий буенча гына тавыш-гауга куптарырга тиешле Алла чынчынлап **Филипп Киркоров** өчен еларга тотынган. Аның күз яше агызуы сәхнә артында да дәвам иткән. Тамашачы исә Пугачеваны үткәннәрен искә төшереп елый дип гөманлаган. Ә үткәннәр чыннан да шундый картинадан гыйбарәт иде шул. Талашлар да, өйдән чыгып китүләр дә, үз-үзенә кул салу белән янаулар да Филипп тарафыннан булып торган. Шуңа да Примадонна тыныч холыклы, сабыр **Максим Галкин**ны сайлагандыр.

ОКЕАН АРТЫ

Үзебезнең Депардье

Франциянең данлыклы актеры гыйнвар башында Россия гражданлыгы алып, үз кешегә әверелде. Россия Президентының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков сүзләренчә, **Жерар Депардье** Сочида Владимир Путин белән очрашып, төшке ашны ашарга да өлгергән. Аның инде кулында Россия паспорты ялтырый, ди. Интернет челтәренә шул гына кирәк тә, Яңа елның калган бәйрәм көннәре Депардьеның булган һәм булмаган гөнаһларын юып үтте. «Бәйрәмнәрдән соң Депардье айнычак һәм Россия гражданлыгыннан баш тартачак», кебекләре иң күбе иде булса кирәк. Ә Россия Саклык банкы җитәкчесе Герман Греф ватанпәрвәрлек хисе белән, Жерар Депардье Россияне тотрыклы икътисади һәм сәяси ил булганы өчен сайлады, дип җиткерде.

Миңа бары 75

Италия актеры **Адриано Челентанога** алай әйтсә дә бик килешә. Үзенең 75 яшьлек юбилее уңаеннан фанатлары өчен сюрприз да әзерләп куйган әле ул. Соцчелтәргә Адриано раритет байлык элгән – 1965 елда төшерелгән «Они шли на Восток» фильмына актерлар сайлап алу күренеше. Әлеге фильмда Адриано уйнаудан баш тарткан булган. Сәбәбе актерның 1964 елда **Клаудия Мори**га өйләнүе белән бәйле. Челентано яшь хатынын калдырып китәргә теләми. Челентано белән Моринның бүген өч баласы бар, гаиләләре күпләр өчен үрнәк. Әлеге фильмнан баш тартып кына актерның карьерасына зыян килмәгән. Күп кенә кино рольләре белән берррәттән Челентано әле рок яратучы музыкант та. Аның 40 альбомы 150 миллион экземпляр белән таралган.

Сәхифәне Гөлнара ЖӘЛИЛОВА әзерләде

Махмырны көтеп алмыйлар, ул үзе килә.

Бибәл Норел

МАХМЫР

Эчкән кешенең хәленә керә белә дә инде Рәсәй хөкүмәте. Менә бит, рәхмәт төшкере, бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына дигәндәй, хөкүмәт Яңа ел бәйрәме уңаеннан никадәр ял көне бирде. Бәгъзеләребез моңа биниһая шатланып, сабыйларча сөенеп, бәйрәмгә хәзерлек эшләрен ике-өч атна алдан ук башлады.

Ләбиб ЛЕРОН

Табынга куелырга тиешле ризык-тәгамнәр, минераль су, сок, лимонад, тархун, фанта, кока-кола, компот, куас, сыра, шампан, шәраб, коньяк, виски, текила, горилка, көмешкә, әлбәттә, аракы ише төрледән-төрле эчемлекләр, кимендә егерме көнгә җитәрлек итеп, мулдан сатып алынды. Туда-суда килеп, анда-монда чыгып, кирәк-кирәкмәскә кыбырсып, бәрелеп-бәргәләнеп йөрмәс өчен моны күпләр, киләчәкне алдан күреп, махсус шулай эшләде. Ал-ял көннәренең берсен дә әрәм-шәрәм итмәенчә, күз карасыдай кадерле вакытның һәр сәгатен, минутын, секундын тулы куәтенә файдаланып, кем әйтмешли, гүләйт тек гүләйт! Шулай иттек тә! Баштагы беренче көндә (гадәттә, 31 декабрьдә) корсакны шартлар чиккә җиткәнче тутырдык. Күнегелгән гадәт буенча, әүвәл оливье салатын, аннары күз ни күрсә – шуны состык: каз-үрдәк түшкәсе дә, дерелдәвек тә, жульен да, өчпочмак белән шулпа да, камырлы-камырсыз балык та, тозлы кыяр-кәбестә белән кара һәм кызыл уылдыклы бутерброд та, мантый-пилмән дә, татарча азу-рагу да, шашлык-машлык та, борай бәлеше (кукмараларча, каз-үрдәкнең муен-канатын да кушып!) белән бәрәңге тәкәсе дә, кыстыбый белән пәрәмәч тә, гөбәдия белән лимон-өрек-кара җимешле пирог та, кыскасы, авыз итмәгән бер ризык та калмады. Инде тамактан бүтән бер тәгам дә үтми башлагач, бар игътибар эчемлекләргә күчте. Менә шул вакытта иллә дә рәхәткә тиендек, малай! Ак-караны аермыйча, фәлән ел бергә яшәгән хатынны, аяк арасында чуалган балаларны танымыйча, күбенгәнче, шешенеп беткәнче, бөер белән бавыр тәмам эштән чыгар чиккә җиткәнче (тефү-тефү, Аллам сакласын берүк!) эчтек, эчтек, эчтек... Күп гасырлык тәҗрибәсе булган урысның үзеннән дә уздырып, аракының шешәсендә генә түгел, мичкәсендә йөздек, күзгә әллә нинди албастылар, җен-пәриләр күренгәнче лыкындык.

«Аракы эчсәң – исертә, самагон эчсәң – кикертә, икесен бергә кушып эчсәң, үрле-кырлы сикертә», – дип җырлый иде өлкән агайлар без бәләкәй чакта. Без дә үстек, үз вакыты җиткәч, без дә җырладык бу җырны. «Үрле-кырлы сикерү»нең нәрсә икәнен үз башыңа төшкәч кенә аңлыйсың икән аны. Бер дә рәхәт әйбер түгел икән ул! Җылар чиккә җиткергән теш сызлаулар да, атлый алмаслык хәлгә китергән бил авыртулар да, күкрәк турысыннан бертуктаусыз яндырып торган сару кайнаулар да махмыр янәшәсендә, миңа калса, гайрәтле ат янында нарасый колын булып кына күренәдер. Әйе, нәкъ шулай дим, чөнки махмырның ни-нәрсә икәнен, аның белән интеккән, минем кебек үләр чиккә җитеп газапланган, җәфаланган кеше үзе генә белә.

Бермәлне (гадәттә, эшкә барасы көнне), кинәт, башың яман чатнаудан, үтерепләр тамагың кибүдән уянып китәсең. Баш бөтенләй эшләми, шуңа күрә, берәр җирдә йөз грамм, һичьюгы ярты шешә чамасы гына булса да сыра калмады микән, дип син әле берни уйламыйсың. Булыр-булмас хәлеңне, барлы-юклы көчеңне тупларга тырышып, капшана-капшана, чайкала-чайкала, абына-сөртенә, кухняга таба барасың, никадәр генә сак булырга тырышсаң да, нәрсәдер идәнгә тәгәри, нидер шалтырый... Кайбер савыт-сабаны ваткач, ниһаять, газ плитәсе өстендәге чәйнүкне кул эзләп таба. Тоткасыннан эләктереп, өскә күтәргәч һәм борынын авызга туры китерү бәхетенә ирешкәч, комсызланып, су эчәргә керешәсең. И ул суның тәмлелекләре! Сүз белән генә аңлатып булмый аны. Шулай итеп, чәйнектәге суны, юшкынына кадәр йотып бетергәч, дерелдәп, гөрелдәп эшләгән суыткычны ачып карыйсың. Анда, сиңа кирәк нәрсәнең юклыгына тәмам ышангач кына, ишекне ябып, теләр-теләмәс кенә урыныңа барып ятасың. Әлбәттә, бүтән йоклап булмый инде. Аның каравы, үзеңә тубалдай тоелган баш шәрифләре акрынлап кына эшләмәкче булып азаплана башлый. Кичә соңгы шешәнең төбенә төшүең хәтереңдә яңара. Егерме көнгә дип тәгаенләнгән запасның тәмам беткәнен, хәтта сырага тамчы да ышаныч калмаганын аңлагач, көрсенеп, авыр сулап куясың. «Никләр эчтем инде?!» дип, эчтән генә үзеңне үзең тиргәргә, сүгәргә тотынасың. Кешечә эчә белмәвең өчен дә битәрлисең. Сәгать телләренең кызу-кызу теркелдәгәне ишетелә. Мин чыгып тайганчы, хатын уянмаса ярар иде, дип, әштер-өштер киенеп, тиз генә урамга атыласың... Суыкка чыккач, әле бая гына үзең тәкрарлаган «Бүтән эчмәс идем» дигән сүзләрне Элдар Рязановның «Язмыш шаяруы яки Җиңел пар белән!» фильмындагы Андрей Мягков герое әйткән «Надо меньше пить» дигәнгә алыштырып, сыра-мазар булса да ярап торыр иде, дигән уйлар белән эшеңә таба юл аласың...

ИКЕ ЭПИГРАММА

ЗӨЛФӘТ

Газинур Моратка

Һәрбер гәзит дәшсен иде
һәр көн:
– Калды сиңа
менә дигән урын –
Түлке шигырь давай!
Давай шигырь!
Шигырь давай, җаным,
Газинурым!

Әхәт Гаффарга

Укыдым
«Тегермән ташы...»н,
Ә. Гаффарның язмасын –
Мондый ташлар
арасына
Кысылырга язмасын!

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1980.)

Р. НУРИЕВ һәм Л.ЛЕРОН шаржы.

Пародия

Әл ЛӘБИБИ

ӘТКӘЙ ЯКИ ШӘРАБЛАРНЫҢ АЛСУ ТӨСЛӘРЕ

Минем әткәй көн дә эшкә китә,
Йолдызларны кайта ияртеп.
Йолдызлар да йоклап китә кебек,
Әтиемнән әкият сөйләтеп.

(Рим Хәсәнов сүзләре һәм көе. Алсу репертуарыннан.)

Минем әткәй көн дә эшкә китә,
Көчкә кайта аннан кичләрен.
Елмаюы аның алып кайта
Шәрабларның алсу төсләрен.

Кушымта:
Әткәй, әткәй, өйгә кайтасың син
Ай нурлары төшкәч юлыңа...
Әкиятеңне башта әни тыңлый,
Уклау тоткан килеш кулына.

Минем әткәй көн дә эшкә китә,
Үз ишләрен кайта ияртеп.
Шешәләр дә йоклап китә кебек,
Әтиемнән әкият сөйләтеп.

Минем әткәй көн дә эшкә китә,
Җырлап кайтып керә төннәрен.
Кара төндә ыңгырашкан чакта
Күршеләрнең ала өннәрен.

Кызыклы ракурс

Ләбиб Лерон Яңа ел бәйрәмендә.

Фотолар Л. ЛЕРОН архивыннан алынды

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

ДУС ЯКИ АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

Гәрәй Рәхимгә



Шундый матур көз бу –
Пәрәвезләр
оча Әдрәнгә...
Баш авырта,
бары бер сум җитми,
Мин чакырам
сине ярдәмгә.

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде

Сүзсез

Ф. МУЛЛАХМӘТ рәсеме.

Балыкны алганда күзенә кара

КУЛЛАНУЧЫГА

Дилбәр ГАРИФ

Балык алырга дип базарга чыккан идем. Ларек эчендә хәйран кеше җыелган. Үз уйларыма чумып басып торып, ун минут үткәнен сизми дә калганмын. Нишләп ун минутмы? Чөнки миннән алдагы бер ир чират башындагы хатынга: «Ун минут буена һаман сайлый алмадыгыз инде. Чиратны тоткарлап тормагыз», – дип җикеренде. Халык тавышлана башлагач, әлеге хатын белән сатучының бәхәсенә колак салдым. Чиратны тоткарлаучы хатын алдындагы балыкның күзенә төртеп күрсәтеп, күзләре тонык бит, яңа кайтарылганы булса, янып торыр иде, дип бәйләнә. Аннан балыкны әйләндерә-тулгандыра башлады. Тагын нәрсәләр кыланган булыр иде, белмим, сатучы сезгә бернәрсә дә сатмыйм дип ачулана башлагач, чыгып китте. Гадәттә, мин үзем алай сайлап азапланмыйм, «балыгыгыз күптәнге түгелме?» дип кенә сорыйм. Сайлый белмәгәч, сатучы сүзенә ышанырга кала инде. Теге хатын бер дә белми түгелдер, әнә күзенә кадәр карап тикшерде бит. Балык сайлаганда тагын нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк? Анысын мин Казан шәһәренең ветеринария берләшмәсе баш табибы **Гали Мөхәммәт улы ИСХАКОВ**тан сораштым.

– Күпләр базардан яки кибеттән алып кайткан балыкларын бозылган иде дип сөйли. Кат-кат әйтәм, алданмас өчен, сатучыдан белешмә кәгазен сорагыз. Анда балыкның сорты, кайда тотылганлыгы, кайчан кайтарылган һәм кайчанга кадәр сатылырга тиешлеге – барысы да язылган. Анда язылганнар да ышандырмаса, саңагына игътибар итәргә кирәк. Бу иң дөрес күрсәткеч. Әгәр дә саңагы кызыл төстә икән, бу балыкны алырга ярый. Саңагы ак яки соры төскә кергән булса, алмавыгыз хәерле. Бармагыгыз белән басып карагыз, шул урын батынкы булып калмаса, ягъни кире үз хәленә кайтса, шулай ук ашарга яраклы балык дигән сүз. Тәңкәсе кипкән булмасын, ул балыкка тыгыз һәм нык берегеп торсын. Майлы балык булып, мае сары төстә булу аның озак сакланганлыгын күрсәтә. Яңа тотылган балыкның тиресен каплаган лайласы үтәкүренмәле була. Лайласы ябышкак һәм тигезсез икән, димәк, күптәнге. Балыкны чистартканда ул кылчыгыннан тиз аерылса яки кылчыклары тырпаеп торса, озак сатылмый яткан балыкны алган булып чыгасыз.

– Хәзер балыкларның башсызларын да саталар. Ысланган балык бозыла башласа, аның башын кисеп алып сатуга куялар дип ишеткәнем бар.

– Булырга мөмкин. Шикләнәсез икән, алмагыз.

– Кыйммәтле балык ите урынына арзанлысын саткан очракта аны аерып буламы?

– Юк. Аны биохимик анализ гына күрсәтә ала.

– Балыкның авырлыгын арттырыр өчен полифосфат сибәләр диләр. Бу дөресме?

– Монысына бик ышанмыйм. Балыкка дымны үзенә тарта торган әйбер сиптерсәләр, ул лаборатория хезмәткәрләре аша үтә алмас иде. Алар аның составын тикшерәләр бит. Шуңа да балыкны кибетләрдән яки базарда сертификаты булган сатучылардан гына алырга кирәк. Шик туса, шунда ук ветеринария табибларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Алар эре базарларда да, сәүдә үзәкләрендә дә бар. Ә менә урам чатларында сатучылардан алып алданмагыз.

– Сәүдә үзәкләре дигәннән, кайвакыт анда балыкларны төреп саталар. Күп очракта алар бозылган була...

– Андыйны гомумән алмаска кирәк. Ул бит вакуумлы төрелгән булырга тиеш. Шулай булмаса, балык озак сакланмый. Безнең һавада нәрсә генә юк, шулар кереп калып, балык бозыла. Кыйммәтле балык булса, акчагызны җилгә генә очырасыз дигән сүз. Гомумән, нәрсәгә аның кыйммәтлесенә кызыгырга? Үзебезнең сулыкларда тотылган балык та тәмле. Файдасы ягыннан да калышмый. Вангага берәү: «Мин Һиндстанда үскән үләнне дә эчтем, Тибеттан кайтарылганын да кулланып карадым», – дигән. Ванга аңа: «Син туган җиреңдә нинди үлән үсә, шуны куллан, аның файдасы тия», – дип җавап кайтарган.

БЕЛЕП ТОР!

Терекөмеш баганасы

Сулыкларга сәнәгатьтән агып чыккан сулар белән бергә авыр металлар да үтеп керә. Бу, үз чиратында, сулыкларда тереклек иткән балыкларда да чагылмый калмый. Диңгез продуктларының кайсында күпме агулы металл булуын түбәндәге таблицадан белә аласыз.

Терекөмеше бик аз

√ Анчоус
√ Кысла һәм лангуст
√ Хек
√ Диңгез сельде
√ Устрица

** олы кешегә балык порциясе – 150-200 гр*

Терекөмеше аз

√ Майлы балык
√ Зубатка
√ Треска
√ Краб
√ Камбала
√ Пикша
√ Макрель

Терекөмеше күп

√ Пеламида
√ Палтус
√ Лобстер

Терекөмеше бик күп

√ Марлин
√ Групер

*Атнасына биш порциягә кадәр ашарга була **

√ Сайда
√ Лосось
√ Сардина
√ Креветка
√ Мерланг
√ Тилапия

Атнасына ике порция

√ Кефаль
√ Мидия
√ Окунь
√ Морской язык
√ Кальмар
√ Форель
√ Тунец

Атнага бер порция

√ Скат
√ Ак тунец
√ Океан сельде

Ашарга ярамый

√ Акула
√ Кылыч балык

ТӘМЛЕ БУЛСЫН

Майонез астындагы кызыл балык

1-1,3 кг кызыл балык
200 гр үсемлек мае
5-6 суган
1,5 стакан сөт
4 аш кашыгы майонез
4 күкәй

Балыкны үсемлек маенда кыздырып алабыз. Түгәрәкләп киселгән суганны майда кыздырып, балык өстенә түшибез. Майонезга сөт, күкәй, тоз салып болгатабыз. Катнашманы балык белән суган өстенә агызып, 15-20 минут газ мичендә пешерәбез.

Сырлы балык

500 гр балык ите
1-2 күкәй
тәменчә тоз, борыч
он
үсемлек мае
200-300 гр сыр

Балык итен юабыз да кисәкләргә бүләбез. Өстенә тоз-борыч сибәбез. Аерым савытка күкәй сытып, аңа тоз салабыз. Тагын бер савытка он, һәм тагын берсенә эре угычта уылган сыр салабыз. Балык итен онда, аннан күкәйдә, соңыннан сырда әвәләп, ике ягын да кыздырабыз.

ИШЕТТЕГЕЗМЕ?

Балыгы бигрәк арзан

Кыйммәтле балык ите урынына кайсы арзанлы балыкныкын сатарга мөмкиннәр



Кефаль урынына ак амур

Кета урынына горбуша



Белорыбица урынына толстолобик



Алабуга (окунь) урынына хек

Тәрәч (треска) урынына пикша



Палтус урынына талисман-балык

ЙОЛДЫЗЛЫ АТНА

КУЧКАР (21.03-20.04)

Ниһаять, күптән уйлап куйган планыгызны гамәлгә ашыру өстендә эшли башларсыз. Әмма аны ярты юлда калдырмавыгыз хәерле. Якыннарыгыз сөйләгәннәргә ышанмау аркасында үзара бәхәскә керү куркынычы бар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-20.05)

Бу атнада бик күп мәгълүмат килеп ирешер. Аларның үзегезгә кирәгенә генә игътибар бирегез. Күп белсәң, тиз картаерсың дигән кебек, юк-бар хәбәр белән башыгызны катырмагыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05-21.06)

Эш урынында килеп чыккан проблемаларны хәл иткәндә эчке интуициягезгә таяныгыз. Ул ялгышырга ирек бирмәс. Ерак туганнарыгыз яки иске танышларыгыздан күңелле хәбәрләр алырсыз.

КЫСЛА (22.06-21.07)

Гайбәтләргә ышанып, ашыгыч карарлар кабул итәргә ашыкмагыз. Югыйсә эш урынында бәхәсләр туарга мөмкин. Тормышыгызда килеп туган вакыйгаларга башкачарак карауны таләп итәрдәй яңалыклар булыр.

АРЫСЛАН (22.07-23.08)

Тырышлыгыгызның төп максаты җитәкчегезнең кушканнарын үтәү булырга тиеш. Барысын да дөрес эшлисезме, кирәк нәрсәләргә омтыласызмы икән – шуның турында уйланыгыз.

КЫЗ (24.08-22.09)

Карьерагызга җитдирәк карау вакыты җитте. Истә тотыгыз: барысы да сезнең кулда. Вак-төяк кебек күренгән нәрсәләрне дә күз уңыннан ычкындырмагыз, бөтен эшнең дә асылына төшенергә тырышыгыз.

ҮЛЧӘҮ (23.09-23.10)

Эш урынында барысы да яхшы. Иң мөһиме – кирәкле мәгълүматны ычкындыра күрмәгез. Якын кешеләрегезгә ярдәмегез кирәк булыр. Аларга авыр вакытта ничек булышырга кирәклеге турында уйланыгыз.

ЧАЯН (24.10-22.11)

Бөтен мәсьәләдә дә үз фикерегездә нык торсагыз, конфликтка керми калмассыз. Бөтен кешегә дә ярарлык, яхшылап уйланган карарларны гына кабул итегез. Ходай сезгә нинди генә сынау бирсә дә, сабыр булыгыз. Вакыт бөтен яраларны да төзәтә.

УКЧЫ (23.11-21.12)

Эшләр сез көткәнчә бармаска да мөмкин. Үзегезнең хаклы булуыгызга ышанычыгыз булмаса, ашыкмавыгыз хәерле. Як-ягыгызга карап, итәк-чабуларыгызны җыеп йөрсәгез, проблемалардан азат булырсыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01)

Хыялларга бирелеп утырырга кирәкмәс. Хәзерге вакытта инициативаны кулдан ычкындырмавыгыз хәерле. Ял көннәрен өйдәгеләргә багышлагыз.

СУКОЯР (21.01-19.02)

Сезнең проблемаларга битараф булмаган кешеләр белән танышырсыз. Игътибарсызлыгыгыз аркасында ниндидер югалтуга дучар булуыгыз бар. Ялгыз Сукоярлар мәхәббәтләрен очратыр.

БАЛЫК (20.02-20.03)

Карарлар кабул иткәндә тизлек, үз-үзеңә ышанганлык һәм эчке сабырлык кирәк булыр. Кунакка барудан баш тартмагыз: анда кирәкле киңәш ишетүегез бар.

Сәхифәне Дилбәр ГАРИФ әзерләде



«Мин күргәнне беркем күрмәсен»

Дөнья кырык сыртлы бит ул – әсәренеп калырлык матурлыгы да, тетрәнерлек кайгы-хәсрәте дә, тәкъдир сынаулары да буа буарлык. Арча районы Югары Пошалым авылында гомер итүче Резеда Галәветдинованың башыннан кичкәннәрен тыңлагач та мин тагын бер кат шуңа инандым. Кырык сыртына кырыкияр кирәк икән дә дөньяның, кырык хәсрәтенә – кырык дәва...

ТӘКЪДИР СЫНАВЫ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА,
Арча, Югары Пошалым

37 яшьлек Резеда апа чыгышы белән Балтач районы Сасна авылы кызы икән. Ике абыйсы, бер энесенә бердәнбер кадерле кыз туган булып үскән ул. Егерме яшендә яратып йөргән егетенә кияүгә чыккан. Бер-бер артлы уллары Рүзәл белән Рәмис туган. Әмма парлы тормыш бәхете татып яшәргә генә язмаган икән. Җиде елдан соң кинәт кенә ире үлеп китә аның. Шуннан соң Резеда ата-ана йортына кайтып төпләнә. Бу вакытта инде әтиләре мәрхүм, нигездә абыстай булган әнисе белән энесе гаиләсе яши. Аларның ике баласы, Резеданың ике улы – өй бала-чага тавышыннан гөжләп тора. Арчадан Илнур исемле егеткә димли башлагач та бераз югалып кала ул. Ничек кабул итәр ул аның улларын, ничек яшәп китәрләр?

Әмма эчми-тартмый торган, ул чагында Арчаның балыкчылык тармагында эшләүче егет тимерне кызуында суга – ике ай дигәндә, Резеданы Югары Пошалымга килен итеп төшерә. Улларын да бик якын итә, алар да әниләре белән бергә күченә. Резеданың яшьтәше булса да, Илнур моңа кадәр гаилә корып карамаган була – әллә шуңа да ул гаиләсе өчен үлеп тора. Шундук озак еллар иясез торган йортка башка чыга, күп итеп терлек булдыра алар.

Әле дә хәтерли Резеда – таудай корсагы белән иренең печән алып кайтышына йөгерә-атлый каршы чыга. Илнур, ике иптәш егете белән ишегалды уртасына йөкне аудара да, эшкә дә керешә. Резеда да чат ябышып эшли, дөбердәтеп дөнья көткән хатын буларак. Башаркан йөк ыргыткан хатынга карап баһадир ирләр дә сүзсез кала – кара син моның егәрлеген, вәт дөнья көтә бу! Әле шактый түгәрәкләнгән көмән белән!..

Инде вакыты җитсә дә, Резеда бала туар алдыннан башланган сызлануларны тоймый. Табибларга күренергә баргач та, инде яшең дә шактый, табарга кирәк, дигәннәренә аптырап кала. Бәй, тулгак булмаган көеме? Бәбиләтергә алып кереп китеп, системалар куйгач та, тулгак ачысын татымый ул. Аның саен аңа тырышырга кушалар: «Балаң үлә, көчән әйдә, тагын-тагын»... Сау-сәламәт баласын күкрәгенә салгач кына Резеда баш авыртуын тоя – шартлыймы бу баш, чатныймы?..

Илнур бер басасы урынга мең басып йөри – 37 яшенә җитеп, көтеп алган беренче нарасые бит! Өйгә чыккач та хатынына кадер-хөрмәтне җәлләми. Ә Резеданың хәле көннән-көн начарая гына. Башта ул каты баш авыртуларына түзә алмый җәфалана. Аннан Илназлары – бер айлык сабыйның кинәт кенә температурасы 39га кадәр күтәрелә. Ана белән бала хастаханәгә кереп ята. Шунда Резеда үзенең чын-чынлап авырый башлаганын тоя – ул өч көн, өч төн рәттән йокламый. Әнисенә – күпләрне өшкереп дәвалаучы абыстайга, үзенең хастасы барлыгын әйтә ул. Балалары хастаханәдән чыгуга, алар янына килеп тә җитә ана. Шул төнне Резеда төнге уникедә хәлләрнең хәтәренә тап була – беркем берни ишетмәгән, күрмәгән җирдән аның күзенә әллә нинәрсәләр күренә башлый, олы улларын уятырга керешә: «Торыгыз, алыгыз киемнәрегезне, өйдән чыгып китегез! Күрмисезмени, килделәр! Торыгыз дим, сезгә әйтәм!» Әнисе кат-кат өшкерә Резеданы. Әмма хатын күзенә күренгән затлардан, колагына ишетелгән шартлаулардан илерүен дәвам итә. Икенче көнне исә биләүсәдәге кечкенә нарасыен анасына атып бәрә: «Алыгыз бу күмерне, күрмисезмени, көеп беткән бу!» «Нишлисең син, – ди анасы. – Бер җире дә көймәгән ләса!» Хатынны им-томчы карчыкларга алып китәләр – тегеләре кул гына селти. Янәсе, моңа безнең теш үтми, бүлнис кирәк.

– Ирем белән сыер саварга чыгам, – дип сөйли Резеда, – башта карап торам – ул инде, бераздан күтәрелеп карасам, әллә кем карап тора... Менә шуннан тынгысызлана башлыйм инде, ул мине көч-хәл белән тынычландыра иде. Үзебезнең районнан абый юллама алып, Казанның Ершов урамындагы «теге» хастаханәгә барганда да кулларымны каерып тотып кына тынычландырганнар. Чөнки миңа әллә нинди кешеләр күренә иде, шартлаулар ишетәм. Имеш, өебез шартлап яна башлаган, терлекләребез тереләй яна...

– Ул вакытта кечкенә балагыз турында уйлар кылә идеме соң?

– Юк, исемә дә кермәде. Казанда хастаханәгә урнаштыргач кына, сөттән ташып шешкән күкрәкләремне савып, кысып бәйләп куйгач кына, бераз искә алдым шикелле. Илнур килеп, бәбиебез үсә, чәбәләнеп ята, сине сагына инде, дип искә төшерергә ярдәм итә иде. Анда бер атна буе көчле дарулар кадап йоклаттылар, аннан дәваладылар. 45 көннән авылга кайттым. Аңарчы ике ай ярымлык булган улымны әнием белән Илнур караган, сөннәтләп куйганнар. Бик елаган ул мин киткәч, ә мин кайтасы көнне иртән көне буе шат булып, кинәт көлеп җибәреп, уйнап яткан. Әни әйтә, сизенде, ахры, кайтасыңны, ди.

> ***Икенче көнне исә биләүсәдәге кечкенә нарасыен анасына атып бәрә: «Алыгыз бу күмерне, күрмисезмени, көеп беткән бу!»***

Бала тапканнан соң башланган депрессия белән хастаханәдә ятучы кеше Резеда гына булмаган анда. Бер хатын үлеп чыккан әнә. Икенче берәвенә, Резедага тигән кебек, ярдәме тигән. Әмма өйгә чыккач та Резеда тиз генә калыбына кайтып утырмаган әле. Пошалымда озак еллар фельдшер булып эшләүче авылдашы «Ходайдан сора» дип киңәш биргән аңа. Резеда исә һәр иртәдә Ходайга ялварган: «Балаларым хакына, ирем хакына, бәхетем хакына»...

Бүген Резеда апаның тормышы көйләнеп киткән инде. Алар иң беренче эш итеп нигезләрен алыштырган. Илназны тапкач бирелгән ана капиталы белән 350 мең сумга өй сатып алганнар, 7 баш эре терлек, сарыклар, казлар тота алар. Колхоз эше белән мантып булмый, хуҗалыктагы шул терлек яшәтә инде, диләр.

– Баштан узган әлеге вакыйгаларны искә дә аласым килми, – ди Резеда апа. – Бүген менә бу бәләкәй кеше (имезлек суырып, бик җитди генә кыяфәттә бөтен җирдә «тәртип» урнаштырып тәпи йөрүче бер яшьлек улына ишарәли. – **Г.Җ.**), берсе Лесхозда, икенчесе мәктәптә укучы олы улларым, ирем белән, Аллага шөкер, яшәп ятабыз. Эштән курыкмыйбыз без, эш кенә булсын. Шөкер, авыр чор артта калды. Аны табиблар да искә төшерергә кирәкми, диде. Ходай Тәгалә ярдәм итте, димен, ирем әйбәт булды. Ул әйбәт булмаса, мине яратмаса, котыла да алмаган булыр идем, бәлки. Без яхшы гына яшәп киткәнгә, кеше күзе тигән булгандыр, дип гоманлыйм хәзер. Аннан, элек без яшәп торган нигездә әни, дога уку да кыен, ди иде. Мине өшкергәндә дә шабыр тиргә бата иде. Баксаң, анда элек яшәгән хуҗаларның язмышы гыйбрәтле булган икән. Бабайның төгәл генә ничек үлүе билгесез, әби исә аның үлеменнән соң тилереп үлгән...

НАХАК СҮЗ — ҖАН ЯРАСЫ

Алсу сыйныф ишеген атлап кергән чакта башка әниләр инде мәш килеп бәйрәмгә әзерләнеп ята иде. Алсуның килеп кергәнен күреп, бөтенесе дә аңа текәлделәр.

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

Эльвина ШИҺАБЕТДИНОВА

«Нәрсә булды?» – дип сорады Гөлназ, иң беренчеләрдән булып. Әйе, ниһаять, акчалар җыелып бетте», – дип сөенечен уртаклашырга ашыкты Алсу, елмая-елмая. Үзе сумкасыннан бер кочак рәсемнәр, открыткалар чыгарып өстәл өстенә җәеп салды. Юк-барны сөйләшә-сөйләшә, кәефләре күтәренке әниләр булачак афиша өчен рәсемнәр сайларга тотындылар. «Кая, акчаларны тагын бер кат саныйк та, тегүчебезгә илтеп тапшырасы булыр», – дигән фикер кертте Гөлназ. Алсу тиз генә үрелеп өстәл өстеннән акча салынган конвертны алырга теләде, ләкин аны таба алмый аптырашта калды. Әле генә шушында куйды бит, аермачык хәтерли. Кая гына китте соң бу каһәр төшкән конверт?

Башка әниләрнең үзенә төбәлгән сораулы карашларын күреп, Алсуның тәннәре чемердәп китте. Кат-кат өстәл өсләрен, парта араларын карау да көткән нәтиҗәләрне бирмәде. Акчалар суга төшкәндәй юк булды. Ә конвертта аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ кырык мең сум акча ята иде бит. Менә табып кара син аны хәзер. Акчаларыннан да бигрәк балалары кызганыч. Җиденче сыйныфта укучы балалар ярты елдан артык театрга әзерләнәләр. Иң мөһиме: ул инглиз телендә булачак һәм аны карарга бөтен мәктәпләр генә түгел, хәтта район мәгариф идарәсеннән дә килергә җыеналар. Ата-аналар театр өчен киемнәр тектерергә акча җыйдылар. Дөресрәге, бу эш белән Алсу шөгыльләнде. Калганнар аңа тиешле сумманы тапшырып кул гына куйдылар. Бүтәннәр аны-моны эндәшмәсәләр дә, Гөлназ Алсуны тетеп ташлады. «Ничек тик торганда шуның кадәр акчаны югалтып була ди, аңламыйм. Үзең алгансыңдыр син аны», – диде ул кайгысыннан нишләргә дә белмәгән хатынга. Алсу бу гаепләрне ишетеп гарьлегеннән үләр дәрәҗәгә җитте. Гөлназның гына үз туксаны туксан. Ул һаман да Алсуны караклыкта гаепләде.

Югалган акча турындагы уйлары аңа өенә кайткачтын да тынгылык бирмәде. Үзенең конвертны кай җирдә югалтырга мөмкин булуы турында озак уйланды ул. Кайларга баруын, кемнәр белән очрашуын кат-кат күз алдыннан үткәрде. Ләкин һич кенә дә моның очына чыга алмады.

Гөлназ исә Алсуны гаепләүдән туктамады. Бөтен кеше алдында бичара хатынны кимсетеп кенә калмыйча, очраган кеше саен аны яманлады, карак дип атады. Бәлки Алсу гаепле түгелдер дип әйтүчеләргә каршы чәчрәп кенә чыкты. Ничек ул алмасын ди инде. Алсуның бертуган энесе бик авыр хәлдә хастаханәдә ята, операция ясау өчен тиз арада күп акча кирәк икән бит, шуны белмисезмени, янәсе. Тик ул егеткә операция күптән булганын, ә моның өчен гаиләнең җиңел машиналарын сатканын белми иде, билгеле.

Бер атна вакыт узгач, Алсуның кызы Әдилә мәктәптән бик дулкынланып кайтты. «Әни, – дип кычкырды ул килеп керешкә, – безнең сыйныфтагы Ирек белән Алисәне кич урамда полиция тоткан. Алардан акчалар һәм кыйммәтле телефон алганнар. Хәзер аларның кайдан килеп чыкканын тикшерәләр». Алсу бу хәбәрне ишетеп уйга калды. «Кызык бит ә, – дип уйлады ул эченнән генә. – Мине гел караклыкта гаепләүче Гөлназның улы Ирекне полиция тикшерә».

Соңрак, Алсу югалткан акчалар Ирек белән Алисәдә табылгач, барлык укытучылар, балалар, ата-аналар аптыраудан телсез калды. Алсуның сумкасыннан китаплар алганда конверт төшереп җибәрүен күргән һәм аны алып, вакытында кире тапшырмаган егет белән кыз кисәк кенә үз кулларына килеп кергән байлык турында берәүгә дә сөйләмәгән булырлар иде, билгеле. Ләкин яңа телефонлы буласылары килә аларның. Сак бүлегендә эшләүчеләр туктатып телефоннарын тикшергән вакытта, Ирекнең кесәсеннән телефонына ияреп биш меңлек акча да килеп чыга. Менә шулай килеп каба караклар.

Сәхифәне Илсөя ЗӘЙНУЛЛИНА әзерләде

ДҮШӘМБЕ
14 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара» (Панорама). Информационно-развлекательная программа (на татарском языке) (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «ЖЕНА ИУДЫ» (12+)
10.30, 01.30 Ретро-концерт (0+)
11.00 «Давайте споем!» (на татарском языке) (6+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Нет от мира сего...» (12+)
14.40 «Твоя професссия» (6+)
14.55 «Быстрая зарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Гостинчик для малышей» (на татарском языке) (0+)
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Мы танцуем и поем» (0+)
16.25 Т/с «МАГНА АУРА»
17.00, 20.00 Новости Татарстана (на татарском языке) (12+)
17.20 «Улыбнись!» Юмористическая программа (12+)
19.00 Документальный фильм (12+)
19.45 «Бизнес Татарстана» (12+)
20.30 «Народ мой...» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30 «Парламентские вести»
14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать» с Михаилом Ширвиндтом
15.50 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
16.35 Премьера. «Ты не один» (16+)
17.05 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «МЕТОД ФРЕЙДА» (16+)
23.30 Ночные новости
23.50 Х/ф «ВСЕ ПУТЕМ» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ВКУС ГРАНАТА» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «МАРЬИНА РОЩА» (12+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Живут же люди!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «ПАУТИНА» (16+)
21.25 Т/с «ЗАЩИТА КРАСИНА» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Т/с «РУССКИЙ ДУБЛЬ» (16+)
01.35 Дикий мир (0+)

ЗВЕЗДА
06.00, 13.15 Д/с «Товарищ комендант». «Комендант Кремля» (12+)
06.55, 09.15 Т/с «ПОД ЛИВНЕМ ПУЛЬ» 1, 4 серия (16+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
11.25 Х/ф «СЕМЬДЕСЯТ ДВА ГРАДУСА НИЖЕ НУЛЯ» (12+)
14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
14.25 Д/с «Оружие XX века» (16+)
15.00, 16.15 Т/с «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 5, 6 серия (16+)
17.25 Д/с «Невидимый фронт» (16+)
18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-3» 1, 2 серия (16+)
22.30 Х/ф «КОНЕЦ ИМПЕРАТОРА ТАЙГИ» (12+)

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00, 13.00 «Званый ужин» (16+)
10.00 Х/ф «СКАЛОЛАЗ»
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Военная тайна с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50 Х/ф «НАЕМНИКИ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Великий Человек-паук» (12+)
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00 «ПАПИНЫ ДОЧКИ» (12+)
08.30 «СВЕТОФОР» (16+)
09.00, 09.30, 13.30, 19.00, 23.45, 00.00 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
10.30, 17.30, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
12.30 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
14.00 Х/ф «ЗНАКОМЬТЕСЬ, ДЖО БЛЭК» (16+)
19.20 «Шрэк» Полнометражный анимационный фильм. США, 2001 г. (12+)
21.00 Х/ф «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
22.00 Х/ф «БРИЛЛИАНТОВЫЙ ПОЛИЦЕЙСКИЙ» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.55 «Все включено» (16+)
05.50, 02.30 «Моя планета»
06.30 «В мире животных» с Николаем Дроздовым
07.00, 08.55, 17.25 Вести-спорт
07.10 «Моя рыбалка»
09.05 Х/ф «И ПРИШЕЛ ПАУК» (16+)
11.00 «Наука 2.0. Опыты дилетанта». Поисковики
11.30 «Наука 2.0. Большой скачок». Радиоволны
12.00 «Местное время. Вести-Спорт»
12.30, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
13.00 Конькобежный спорт. Чемпионат Европы. Трансляция из Нидерландов
13.55 Биатлон. Кубок мира. Трансляция из Германии
17.35 Х/ф «ТЕНЕВОЙ ЧЕЛОВЕК» (16+)
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Химки» (Россия) – «Туров» (Польша). Прямая трансляция
21.15 Неделя спорта
22.05 «Суперкар: инструкция по сборке»
23.15 Х/ф «РОБОКОП: ВО ИМЯ ПРАВОСУДИЯ» (16+)

КУЛЬТУРА
07.00 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 01.40 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН» 1 серия
12.10 «Секретные проекты». «Мобильный для Лубянки»
12.40 Д/ф «Сергей Бонди. Огонь в очаге»
13.20 Д/ф «Химба снимают!»
14.15 «Линия жизни». Владимир Мартынов. (*)
15.10 «Пешком...» Москва женская
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «СЕЛО СТЕПАНЧИКОВО И ЕГО ОБИТАТЕЛИ» 1 серия
17.20 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Лион. Красота, висящая на шелковом шнуре»
17.35 «Звезды мирового фортепианного искусства». Борис Березовский
18.35 Д/с «Искусство Германии»
19.45 Главная роль
20.05 «Сати. Нескучная классика...» с Николаем Цискаридзе и Евгением Князевым
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №5
21.30 Д/ф «Ночные летописи Геннадия Доброва»
22.15 «Тем временем»
23.00 К 150-летию со дня рождения Константина Станиславского. «После «Моей жизни в искусстве». Авторская программа Анатолия Смелянского. 1 часть
23.55 Документальная камера. «Профессия кинокритик, или Необходимость современности»

СИШӘМБЕ
15 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара» (Панорама). Информационно-развлекательная программа (на татарском языке) (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «ЖЕНА ИУДЫ» (12+)
10.30, 01.30 Ретро-концерт (0+)
11.00 «Головоломка». Телевизионная игра (на татарском языке) (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
13.00 «Реквизиты былой суеты» (12+)
13.15 Документальные фильмы (12+)
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Деревенские посиделки». Фольклорная программа (на татарском языке) (6+)
14.55 «Быстрая зарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Гостинчик для малышей» (на татарском языке) (0+)
15.30 «Молодежная остановка» (12+)
16.00 «Tat-music» (12+)
16.25 Т/с «МАГНА АУРА»
17.00, 20.00 Новости Татарстана (на татарском языке) (12+)
17.20 «Улыбнись!» (12+)
19.00 Д/ф «Самые опасные места». «Вселенная» (12+)
20.30 «Татарские народные мелодии» (0+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)
00.00 «Автомобиль» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Мир культуры»
09.20 «Рядовые России»
14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать» с Михаилом Ширвиндтом
15.50 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
16.35 Премьера. «Ты не один» (16+)
17.05 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «МЕТОД ФРЕЙДА» (16+)
23.30 Ночные новости «Городские пижоны»
23.50 «Задиры». Новый сезон (S) (16+)
01.00 Х/ф «МОРСКОЙ ПЕХОТИНЕЦ» (16+)
02.40, 03.05 Х/ф «ДЖЕССИ СТОУН: РЕЗКОЕ ИЗМЕНЕНИЕ» (16+)
04.20 «Контрольная закупка» до 04.50

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ВКУС ГРАНАТА» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «МАРЬИНА РОЩА» (12+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Поедем, поедим!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «ПАУТИНА» (16+)
21.25 Т/с «ЗАЩИТА КРАСИНА» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Т/с «РУССКИЙ ДУБЛЬ» (16+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.15, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.25, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
06.55 Т/с «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 5, 6 серия (16+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.15 Х/ф «КОНЕЦ ИМПЕРАТОРА ТАЙГИ» (12+)
11.00 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-3» 1, 2 серия (16+)
13.15 Д/с «Товарищ комендант». «Комендант Берлина» (12+)

14.25 Д/с «Оружие XX века» (16+)
15.00, 16.15 Т/с «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 7, 8 серия (16+)
17.25 Д/с «Невидимый фронт» (16+)
19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-3» 3, 4 серия (16+)
22.30 Х/ф «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ...» (16+)

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00, 13.00, 04.00 «Званый ужин» (16+)
10.00, 02.00 «Следаки» (16+)
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Территория заблуждений с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Великий Человек-паук» (12+)
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00 «ПАПИНЫ ДОЧКИ» (12+)
08.30 «СВЕТОФОР» (16+)
09.00, 13.10, 13.30, 16.45, 19.00, 00.00, 00.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30, 21.00 Х/ф «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
10.30, 17.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 «Шрэк» Полнометражный анимационный фильм. США, 2001 г. (12+)
14.00 «Галилео». Научно-развлекательный журнал. Ведущий – Александр Пушной (0+)
15.00 Х/ф «БРИЛЛИАНТОВЫЙ ПОЛИЦЕЙСКИЙ» (16+)
19.20 «Кунг-фу Панда» (6+) Полнометражный анимационный фильм. США, 2008 г.
22.00 Х/ф «ДЕВУШКА МОИХ КОШМАРОВ» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50 «Вопрос времени». Бытовые подходы
06.20 «Моя планета»
07.00, 09.00, 12.00, 16.50, 22.50 Вести-спорт
07.10 «Диалоги о рыбалке»
08.40, 11.40 Вести.ru
09.10 Х/ф «СТЭЛС В ДЕЙСТВИИ» (16+)
11.10 «Наука 2.0. ЕХперименты». Беспилотники
12.10, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
12.40 «Братство кольца»
13.10 Х/ф «И ПРИШЕЛ ПАУК» (16+)
15.00 Х/ф «РОБОКОП: ВО ИМЯ ПРАВОСУДИЯ» (16+)
17.05 Смешанные единоборства. Bellator. Трансляция из США (16+)
19.25 Хоккей. КХЛ. «Северсталь» (Череповец) – «Локомотив» (Ярославль). Прямая трансляция
21.45 «АЛСИБ. Секретная трасса»
23.05 Х/ф «РОБОКОП: СХВАТКА» (16+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН» 2 серия
12.10 «Секретные проекты». «Космические страсти по «Алмазу»
12.40 Д/ф «Владимир Набоков. Русские корни»
13.30 Д/с «Малый ледниковый период»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №1
15.10 «Пятое измерение». Авторская программа И. Антоновой. (*)
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «СЕЛО СТЕПАНЧИКОВО И ЕГО ОБИТАТЕЛИ» 2 серия
17.20 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Бремен. Сокровищница вольного города»
17.35 «Звезды мирового фортепианного искусства». Катя Буниатишвили
18.35 Д/с «Искусство Германии»
19.45 Главная роль
20.05 Власть факта. «Всемирная история чая»
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №6
21.30 «Больше, чем любовь»
22.15 «Игра в бисер» с Игорем Волгиным. «Лирика Сергея Есенина»
23.00 К 150-летию со дня рождения Константина Станиславского. «После «Моей жизни в искусстве». Авторская программа Анатолия Смелянского. 2 часть
23.50 Х/ф «НАННЕРЛЬ, СЕСТРА МОЦАРТА»

ЧӘРШӘМБЕ
16 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара» (Панорама). Информационно-развлекательная программа (на татарском языке) (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 01.00 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «ЖЕНА ИУДЫ» (12+)
10.30 Ретро-концерт (0+)
11.30 «Народ мой...» (на татарском языке) (12+)
12.00, 21.30 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
13.00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13.30 «Среда обитания» (12+)
14.00, 18.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Актуальный ислам» (6+)
14.25 «Наставник» (на татарском языке) 6+
14.55 «Быстрая зарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Гостинчик для малышей» (0+)
15.30 «Мы – внуки Тукая» (6+)
15.45 «Твоя профессия» (на татарском языке) (6+)
16.00 «Мы танцуем и поем» (0+)
16.25 Т/с «МАГНА АУРА»
17.00, 20.00 Новости Татарстана (на татарском языке) (12+)
17.20 «Улыбнись!» (12+)
19.00 «Перекресток мнений» (на татарском языке) (12+)
20.30 «Молодежная остановка» (на татарском языке) (12+)
22.30 Волейбол. Лига Чемпионов. «Берлин» (Германия) – «Зенит» (Россия). Трансляция из Германии (6+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать» с Михаилом Ширвиндтом
15.50 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
16.35 Премьера. «Ты не один» (16+)
17.05 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Дмитрий Певцов, Ольга Дроздова многосерийном фильме «Ангел в сердце» (S) (12+)
23.30 Ночные новости «Городские пижоны»
23.50 «Гримм» (S) (16+)
00.40, 03.05 Х/ф «ПОДАЛЬШЕ ОТ ТЕБЯ» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ВКУС ГРАНАТА» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 Т/с «МАРЬИНА РОЩА» (12+)

НТВ
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Чудо техники» с Сергеем Малозёмовым (12+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «ПАУТИНА» (16+)
21.25 Т/с «ЗАЩИТА КРАСИНА» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Т/с «РУССКИЙ ДУБЛЬ» (16+)
01.35 Квартирный вопрос (0+)

ЗВЕЗДА
14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
15.00 Т/с «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» 1, 2 серия (16+)
17.10 Д/ф «Тайна гибели «Титаника» (12+)
18.00, 22.00 НОВОСТИ
18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.30 Т/с «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-3» 5, 6 серия (16+)
22.30 Х/ф «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» (16+)
23.50 Х/ф «ТАНКОДРОМ» (12+)

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30 ПРЕМЬЕРА. «Пища богов» (16+)
09.30 Жить будете (16+)
10.00 «Следаки» (16+)
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
12.30 «Новости 24» (16+)
13.00 «Званый ужин» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00 «Не ври мне!» (16+)
17.00, 18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 ПРЕМЬЕРА. «Нам и не снилось»: «Миллион на выданье» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50, 02.40 Х/ф «16 КВАРТАЛОВ»

СТС-КАЗАН
05.59 На СТС до 09.00 профилактические работы.
09.00, 13.10, 13.30, 19.00, 23.40, 00.00 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30, 21.00 Х/ф «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
10.30, 17.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 «Кунг-фу Панда» (6+) Полнометражный анимационный фильм. США, 2008 г.
14.00 «Галилео». Научно-развлекательный журнал. Ведущий – Александр Пушной (0+)
15.00 Х/ф «ДЕВУШКА МОИХ КОШМАРОВ» (16+)
19.25 «Мадагаскар» (6+) Полнометражный анимационный фильм. США, 2005 г.
22.00 Х/ф «МЕДАЛЬОН» (16+)
00.30 Х/ф «ЖИЗНЬ ПО ДЖЕЙН ОСТИН» (16+)
02.30 Х/ф «ПРЕСТУПНИК» (16+)

СПОРТ
10.00 Х/ф «РОБОКОП: ВО ИМЯ ПРАВОСУДИЯ» (16+)
11.45, 02.40 Вести.ru
12.05, 22.50 Вести-спорт
12.15, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
12.45 Х/ф «МОТОЦИКЛИСТЫ» (16+)
13.35 Х/ф «РОБОКОП: СХВАТКА» (16+)
15.25 «Основной состав»
15.55 Хоккей. КХЛ. «Авангард» (Омская область) – ЦСКА. Прямая трансляция
18.15 Профессиональный бокс
19.25 Хоккей. КХЛ. «Спартак» (Москва) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
21.45 «Полигон»
22.15, 02.10 «Рейтинг Баженова. Человек для опытов»
23.05 Х/ф «РОБОКОП: ВОСКРЕШЕНИЕ» (16+)

КУЛЬТУРА
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 01.55 Т/с «ПЕРРИ МЭЙСОН» 3 серия
12.10 «Секретные проекты». «Ракетный миф»
12.40 Документальная камера. «Профессия кинокритик, или Необходимость современности»
13.20 Д/ф «Балахонский манер»
13.30 Д/с «Малый ледниковый период»
14.05 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Занзибар. Жемчужина султана»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №2
15.10 Красуйся, град Петров! Зодчий Вениамин Стуккей. (*)
15.40, 19.30, 23.30 Новости культуры
15.50 Спектакль «ОБЫКНОВЕННАЯ ЖИЗНЬ»
16.50 Д/ф «Волею судьбы. Евгений Чазов»
17.35 «Звезды мирового фортепианного искусства». Давид Фрай
18.35 Д/с «Искусство Германии»
19.45 Главная роль
20.05 «Абсолютный слух». Альманах по истории музыкальной культуры
20.45 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №7
21.30 Д/ф «Хамдамов на видео»
22.15 Магия кино. Ведущие М. Борзенков и О. Шишкин
23.00 К 150-летию со дня рождения Константина Станиславского. «После «Моей жизни в искусстве». Авторская программа Анатолия Смелянского. 3 часть
23.50 Х/ф «МОЙ ДОМ ПОЛОН ЗЕРКАЛ» 1 серия
01.40 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Бремен. Сокровищница вольного города»

ПӘНҖЕШӘМБЕ
17 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». Информационно-развлекательная программа (на татарском языке) (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30 Т/с «ЖЕНА ИУДЫ» (12+)
10.30, 01.30 Ретро-концерт (0+)
11.00 «Перекресток мнений» (на татарском языке) (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
13.00 Телефильмы «Карл Фукс», «Стахеевы» и «Николай Фешин. Навсегда в России» (12+)
14.00, 19.15, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.15, 00.00 «Волейбол». Тележурнал (12+)
14.45 «Путь» (12+)
14.55 «Быстрая зарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Гостинчик для малышей» (на татарском языке) (0+)
15.30 «Школа» (на татарском языке) (6+)
15.45 «Смешинки» (на татарском языке) (6+)
16.00 «Tat-music» (12+)
16.15 Т/с «МАГНА АУРА»
16.45, 20.00 Новости Татарстана (на татарском языке) (12+)
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Трактор» (Челябинск) – «Ак Барс» (Казань). Трансляция из Челябинска
20.30 «Татары» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Город мастеров»
09.20 «Яңа сәлам»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать» с Михаилом Ширвиндтом
15.50 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
16.35 Премьера. «Ты не один» (16+)
17.05 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Дмитрий Певцов, Ольга Дроздова многосерийном фильме «Ангел в сердце» (S) (12+)
23.30 Ночные новости
23.50 «На ночь глядя» (12+)
00.50 Х/ф «СУПЕРПЕРЦЫ» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
